**КАЗАН ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ**
ФИЛОЛОГИЯ ҺӘМ МӘДӘНИЯТАРА
БАГЛАНЫШЛАР ИНСТИТУТЫ
***Татар тел белеме кафедрасы***

**Р.Х. МИРЗАҺИТОВ, Р.К. СӘГЪДИЕВА, Д.Х. ХӨСНЕТДИНОВ**

# ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ТЕЛЕ СИНТАКСИСЫ (ТАБЛИЦАЛАРДА)

Югары уку йортлары өчен уку-укыту кулланмасы

Казан – 2019

**УДК 8-81**
**ББК 6/8**

*КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты Гыйльми советының уку-укыту методик комиссиясе карары нигезендә бастырыла*
*(5 нче номерлы беркетмә, 15 февраль, 2019 ел)*

**Фәнни мөхәррире**:
филология фәннәре кандидаты, доцент **Р.С. Нурмухаметова**
Рецензентлар:
филология фәннәре кандидаты, доцент **Э.Х. Кадирова**
филология фәннәре кандидаты, доцент **М.М. Шакурова**

**Мирзаһитов Р.Х.,**
**Хәзерге татар теле синтаксисы (таблицаларда):** Югары уку йортлары өчен уку-укыту кулланмасы / Р.Х. Мирзаһитов, Р.К. Сәгъдиева, Д.Х. Хөснетдинов. – Казан, 2019. – 65 б.

Кулланма югары уку йортының татар филологиясе бүлегендә белем алучы студентларга юнәлдерелгән. Хезмәттә хәзерге татар теле синтаксисының төп кагыйдәләре таблицаларга салып бирелә. Тәкъдим ителгән уку-укыту әсбабы студентларга теоретик материалны җиңел үзләштерергә ярдәм итә. Теоретик мәгълүматларны ни дәрәҗәдә үзләштергәнлекне ачыклау максатыннан, ахырдан гамәли эшләр, тестлар урнаштырылды.

© Казан федераль университеты, 2019
© Мирзаһитов Р.Х., Сәгъдиева Р.К., Хөснетдинов Д.Х., 2019

# ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ТЕЛЕ СИНТАКСИСЫ

| СҮЗЛӘР БӘЙЛӘНЕШЕ | |
|---|---|
| **тезүле бәйләнеш** | **ияртүле бәйләнеш** |
| *Бакчада ал, кызыл һәм сары чәчәкләр үсә.* | *Бакчада кызыл чәчәкләр үсә.* |

Сөйләмдә сүзләр бер-берсенә ияреп тә, бер-берсе белән тезелеп тә килә алалар. Димәк җөмләдәге сүзләр арасында **тезүле бәйләнеш** һәм **ияртүле бәйләнеш** була.

Тезүле бәйләнештә килгән сүзләрнең барысы да бер генә сүзгә ияреп киләләр. Мәсәлән: *Мин укыйм, язам, сөйлим. Китапларны һәм дәфтәрләрне сумкама салдым.* Тезүле бәйләнештә килгән җөмлә кисәкләре **тиңдәш кисәкләр** дип атала.

| ТЕЗҮЛЕ БӘЙЛӘНЕШНЕ БЕЛДЕРӘ ТОРГАН ЧАРАЛАР | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **интонация** | | **тезүче теркәгечләр** | | |
| санау | каршы кую | җыючы | каршы куючы | бүлүче |
| ***Каргалар, чыпчыклар*** *җылы якка китмиләр.* | *Мин* ***укыдым – аңламадым***. | ***Әнием дә, әтием дә*** *мәктәптә эшлиләр.* | *Мин* ***укыдым, ләкин аңламадым.*** | *Яз көне бакчама* ***кызыл я сары*** *чәчәкләр утыртырмын.* |

| ТИҢДӘШ КИСӘКЛӘР АРАСЫНДА ТЫНЫШ БИЛГЕЛӘРЕ | | | | |
|---|---|---|---|---|
| өтер | | | сызык | тыныш билгесе куелмый |
| санау интонациясе | *ләкин<br>ә<br>әмма* | *да, да<br>әле, әле<br>ни, ни* | каршы кую интонациясе | *һәм<br>да (дә)<br>я (яисә), (яки)* |
| ***Китапларны, дәфтәрләрне*** *өстәл өстенә куйдым.* | *Мин* ***укыдым, ләкин аңламадым.*** | ***Әнием дә, әтием дә*** *мәктәптә укыталар.* | ***Бардым – күрмәдем.*** | ***Алсу һәм Ләйсән*** *8 нче сыйныфта укыйлар.* |

Җөмләдә тиңдәш кисәкләрнең барысын бергә җыеп, гомумиләштереп әйтә торган ***барлык, бөтен нәрсә, һәммәсе, бөтенесе, бар да, һәркайда, һәрвакыт*** кебек сүзләр килә. Алар **гомумиләштерүче сүзләр** дип атала.

Гомумиләштерүче сүзләр тиңдәш кисәкләрнең алдыннан да, алардан соң да урнаша ала. Тиңдәш кисәкләр алдыннан килгән гомумиләштерүче сүздән соң **ике нокта** (**:**), тиңдәш кисәкләрдән соң килгән гомумиләштерүче сүз алдыннан **сызык** (–) куела.
Бер үк җөмләдә гомумиләштерүче сүзләр тиңдәш кисәкләрнең алдыннан да, алардан соң да урнаша ала. Кагыйдә белән бәйле тиешле тыныш билгеләре куела.

Сөйләм барлыкка килсен өчен, сүзләрне тезеп кенә китеп булмый. Аралашканда без сүзләрне төрле формаларга куябыз, бер сүзне икенче сүзгә ияртәбез. Сүзләрнең бер-берсенә ияреп килүләре нәтиҗәсендә **ияртүле бәйләнеш** хасил була.

| ИЯРТҮЛЕ БӘЙЛӘНЕШ | | | | |
|---|---|---|---|---|
| кушымча | фигыль формасы | бәйлек, бәйлек сүз | сүз тәртибе | янәшә тору |
| *Мин укыйм. Мәктәптә уку, шәһәрдә яшәү.* | *Укып утыру, барасы юл, укырга бару.* | *Әни белән бару, урам аша чыгу, укырга дип килү.* | *Күлмәк кызыл. Кызыл күлмәк.* | *Тиз уку, хат язу, бүген кайту.* |

| ИЯРТҮЛЕ БӘЙЛӘНЕШ | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **ҖӨМЛӘ** | | **СҮЗТЕЗМӘ** | | | | |
| зат-сан кушымчалары | сүз тәртибе | кушымчалар | фигыль формалары | бәйлек, бәйлек сүз | сүз тәртибе | янәшә тору |
| *Без укыйбыз.* | *Агачлар матур.* | *Әнинең сүзе.* | *Яза торган хикәя.* | *Күрер өчен килү.* | *Матур агачлар.* | *Матур язу.* |

| СҮЗ | СҮЗТЕЗМӘ | ТЕЗМӘ СҮЗ |
|---|---|---|
| билгеле бер мәгънәгә ия булган авазлар тезмәсе | бер әйберне (эшне) аңа охшаш башка әйбердән (эштән) аерып әйтү | ике яки берничә сүзнең бер атама белдерүе |
| *җиләк*<br>*диңгез* | *кызыл җиләк*<br>*диңгездә коену* | *кура җиләге*<br>*Кара диңгез* |

| |
|---|
| Сүз (*күз*), ия белән хәбәр (*Дәрес башланды*), тезмә сүз (*дәү әнием*), фразеологизм (*колак салу*), тиңдәш кисәкләр (*әни һәм әти*) сүзтезмә түгел. |

| |
|---|
| Җөмләдән сүзтезмәләрне аерып чыгарганда, ияртүче фигыль һәрвакыт исем фигыль формасында алына. |

| СҮЗТЕЗМӘ | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **ИЯРТҮЧЕ СҮЗ** | | | | | | |
| исем | фигыль | сыйфат | сан | рәвеш | алмашлык | хәбәрлек сүз |
| *минем* ***китап*** | *китап* ***уку*** | *әни шикелле* ***матур*** | *китапның* ***икесе*** | *шактый* ***озак*** | *китапның* ***монысы*** | *миндә* ***бар*** |

| |
|---|
| Сүзтезмәдә бер сүз икенчесенә ияреп килә. Ияреп килгәне – **ияртүче**, ә ияртеп килгәне **ияртүче сүз** дип атала. Ияртүче кисәк кайсы сүз төркеменә караса, сүзтезмә шул исем белән атала. Мәсәлән: *кызыл яулык* – исем сүзтезмә, *урамга чыгу* – фигыль сүзтезмә һ.б. Татар телендә **исем**, **фигыль**, **сыйфат**, **сан**, **рәвеш**, **алмашлык** һәм **хәбәрлек сүз** сүзтезмәләр бар. |

| |
|---|
| Сүзтезмәдә иярүче сүз теләсә нинди мөстәкыйль сүз (исем, фигыль, сыйфат, сан, рәвеш, алмашлык) булырга мөмкин. |

| **ҖӨМЛӘ КИСӘКЛӘРЕ** | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Баш кисәкләр | | Иярчен кисәкләр | | | | Модаль кисәкләр | |
| ия | хәбәр | аергыч | тәмамлык | хәл | аныклагыч | эндәш сүз | кереш сүз |
| Алсу, син кызыл алмаларны тартмага, ягъни яшел савытларга, зинһар, җый. | | | | | | | |
| син | җый | кызыл | алмаларны | тартмага | яшел | Алсу | зинһар |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | савытларга | | |

Татар телендә җөмлә кисәкләре зур өч төркемгә аерыла: **баш**, **иярчен** һәм **модаль** кисәкләр.

Җөмләнең структур үзәген төзи торган иң әһәмиятле кисәкләре **баш кисәкләр** дип атала. Баш кисәкләргә **ия** (подлежащее) белән **хәбәр** (сказуемое) керә.

Җөмләнең башка сүзгә буйсынмаган баш кисәге **ия** дип атала. Иянең төп үзенчәлекләре:

1. Ия һәрвакыт **баш килештә** килә: *Мәктәп зур.*

2. Иягә ***-ны/-не*** һәм ***-ның/-нең*** кушымчаларын куеп карап булмый: *Мин ~~күлмәк~~ (-не) юдым. Мин ~~әни~~ (-нең) күлмәген юдым.*

3. Ия янында **бәйлек** һәм **бәйлек сүзләр** килми: *Мин театрга ~~әни~~ белән барам.*

| **ИЯ** | |
|---|---|
| исем | *Алмаз мәктәпкә китте.* |
| алмашлык | *Ул 8 нче сыйныфта укый.* |
| исемләшкән сыйфат | *Кызыл – матур төс.* |
| исемләшкән рәвеш | *Безнең сыйныфта күпләр спорт түгәрәгенә йөри.* |
| исемләшкән сан | *Биремне икебез тактага язып эшлибез.* |
| исемләшкән фигыль | *Уку – авыр эш.* |

Ия баш килештәге **исемнәр**, **алмашлыклар** һәм **исемләшкән сүз**

| |
|---|
| **төркемнәре** белән белдерелә. |

| ИЯ | |
|---|---|
| **гади** | **тезмә** |
| *Алсу мәктәптә укый.*<br>*Сары яфраклар оча.* | *Безне Алсу Хәмитовна укыта.*<br>*Үги ана яфрагы үсә.* |

| |
|---|
| Ия төзелеше ягыннан ике төрле: **гади** һәм **тезмә** була.<br>Ияләр **тиндәшләнеп** килә алалар.<br>Ия составында **күплек** һәм **тартым кушымчалары** булырга мөмкин. |

| |
|---|
| Җөмләнең ия турында хәбәр итә һәм аңа ияреп килә торган баш кисәге **хәбәр** дип атала. |

| ХӘБӘР | |
|---|---|
| **Исем хәбәр** | **Фигыль хәбәр** |
| исем, алмашлык, сан, сыйфат, рәвеш, исем фигыль, аваз ияртеме, хәбәрлек сүз, бәйләгеч һәм модаль сүз төркемнәре | фигыль |
| *Мин – укучы. Күлмәк матур.*<br>*Көндәлегем юк.* | *Көз җитте. Укучылар мәктәптә укый башладылар.* |

| |
|---|
| Хәбәрләр төрле сүз төркемнәре белән белдерелә ала. Кайсы сүз төркеме белән белдерелүенә карап, алар ике зур төркемгә бүленәләр. Фигыль сүз төркеме белән белдерелсә, ул – **фигыль хәбәр**, калган сүз төркемнәре белән |

| |
|---|
| белдерелсә, **исем хәбәр** дип атала. |

| **ИСЕМ ФИГЫЛЬ** | | |
|---|---|---|
| **Гади исем фигыль** | **Тезмә исем фигыль** | **Кушма исем фигыль** |
| 1 сүз (фигыль түгел) | ике мөстәкыйль мәгънәле сүз (фигыль катнашмый) | гади + ярдәмче сүз тезмә |
| *Алсу – укучы.*<br>*Без бишәү.*<br>*Мәктәп зур.*<br>*Китабым бар.* | *Укытучыбыз – Миләүшә Илгизовна.*<br>*Безнең мәктәп – зур мәктәп.*<br>*Бу өй калай түбәле.* | *Алсу укучы икән.*<br>*Китабым бар иде.*<br>*Укытучыбыз Миләүшә Илгизовна икән.*<br>*Безнең мәктәп зур мәктәп бит.* |

| **ФИГЫЛЬ ХӘБӘР** | | | |
|---|---|---|---|
| **Гади фигыль хәбәр** | **Тезмә фигыль хәбәр** | | **Кушма фигыль хәбәр** |
| 1 фигыль | фразеологизмнар | сүз + *ит, бул, кыл* | гади + ярдәмче сүз тезмә |
| *Мин укыйм.* | *Ул урамга күз ташлады.* | *Дәрес дәвам итә.* | *Мин укый башладым.*<br>*Ул урамга күз ташлаган иде.*<br>*Дәрес дәвам итә икән.* |

Төзелеше (структурасы) ягыннан исем хәбәрләр дә, фигыль хәбәрләр дә **гади**, **тезмә** һәм **кушма** булалар.

Гадәттә, җөмләләрдә ике баш кисәк тә кулланыла: *Яфраклар* *саргайды*. Кайбер очракларда җөмләдә бер генә баш кисәк файдаланырга мөмкин: *Көз*. *Китап укыйм*.

Татар телендә, гадәттә, ия хәбәрдән алда килә. Бу **туры сүз тәртибе** була. Шигърияттә, җанлы сөйләмдә һәм тойгылы җөмләләрдә ия хәбәрдән соң да урнашырга мөмкин. Бу күренеш **кире сүз тәртибе**, ягъни **инверсия** дип атала.

Җөмләнең хәбәре баш килештәге исем, алмашлык, сан һәм исем фигыль белән белдерелсә, ия белән хәбәр арасына **сызык** куела.
Хәбәре исем яки исемләшкән сүзләр белән белдерелгән җөмләләрдә, ияне көчәйтеп, аннан соң *ул, бит* көчәйтү кисәкчәсе килсә, сызык әлеге кисәкчәдән соң куела. Әлеге кисәкчәләр хәбәрдән соң да килә ала.

Җөмләдә баш кисәкләр берәр генә булса, ул **гади җөмлә** була. Ике яисә аннан да күбрәк баш кисәкләре булган җөмлә – **кушма җөмлә**.

| **ҖӨМЛӘ** | | | |
|---|---|---|---|
| **ГАДИ ҖӨМЛӘ** | | | **КУШМА ҖӨМЛӘ** |
| *Мин урманда яфраклар җыям*. | *Алсу һәм Ләйсән урманда яфраклар* | *Марат укый, яза, сөйли*. | *Алсу чәчәкләр җыя, Марат җир казый*. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | *жыялар*. | | |

| |
|---|
| Баш кисәкләр тиңдәшләнеп килгән очракта, гади җөмлә хасил була. |

| |
|---|
| Җөмләнең баш кисәкләре, ягъни ия белән хәбәр, җөмлә оештыра. Иярчен кисәкләр җөмләне җәенкеләндерә, тулылындыра. Исеңдә калдыр: сөйләм барлыкка килсен өчен, җөмләнең баш кисәкләре дә, иярчен кисәкләре дә кирәк! |

| |
|---|
| Исемгә ияреп килгән иярчен кисәк **аергыч** (определение) дип атала. Аергычны иярттеп килгән сүз **аерылмыш** була. |

| **АЕРГЫЧ** | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| исем | сыйфат | алмашлык | сан | рәвеш | фигыль |
| ***Агачның*** *яфраклары коела.* | ***Сары*** *яфраклар коела.* | ***Минем*** *әнием матур.* | ***Өч*** *каен үсә.* | ***Күп*** *кеше килгән.* | ***Укыган*** *бала белә.* |

| |
|---|
| Аергыч **исем**, **сыйфат**, **алмашлык**, **сан**, **рәвеш** һәм **фигыль** белән белдерелә. |

| **АЕРГЫЧ** | |
|---|---|
| *Бакчада кызыл, сары, зәңгәр чәчәкләр үсә.* | *Һавада зур кызыл шар очы.* |
| исемне бер яктан гына ачыклый | исемне төрле яктан ачыклый |
| **ТИҢДӘШ АЕРГЫЧЛАР** | **ТИҢДӘШ ТҮГЕЛ АЕРГЫЧЛАР** |

| |
|---|
| Затны яисә әйберне бер яктан гына ачыклап килгән аергычлар **тиңдәш аергычлар** дип атала. Затны яисә әйберне төрле яктан ачыклап килгән аергычлар **тиңдәш түгел аергычлар** була. Тиңдәш аергычлар арасында да, тиңдәш түгел аергычлар арасында да тезүле бәйләнеш. Ләкин тиңдәш түгел аергычлар арасына бернинди дә тыныш билгесе куелмый. |

| |
|---|
| Аергыч, гадәттә, аерылмыш алдыннан урнаша. Сирәк булса да аергыч аерылмыштан соң да килә. Бу күренеш **кире сүз тәртибе**, ягъни **инверсия** дип атала. |

| |
|---|
| Җөмләдә фигыль белән белдерелгән кисәкне ачыклап, эш-хәлнең үтәлүенә бәйле затны, әйберне күрсәтә торган иярчен кисәк **тәмамлык** дип атала. Иярттүче сүзгә нинди чара ярдәмендә ияргүенә бәйле, алар **туры** һәм **кыек тәмамлыкларга** бүленә. |

| **ТУРЫ ТӘМАМЛЫК** | | | | |
|---|---|---|---|---|
| ***-ны/-не, -ын/-ен*** | | ***-ырга/-ергә*** | ***-дан/-дән*** | ***-га хәтле*** |
| *Мин* ***әнине*** *яратам.*<br>*Ул* ***әнисен*** *ярата.* | *Мин* ***китап*** *(-ны) укыйм.* | *Мин сине* ***җырларга*** *өйрәтәм.* | *Ул минем* ***чәчтән*** *тартты.* | ***Казларга хәтле*** *каңгылдаша.* |

| **КЫЕК ТӘМАМЛЫК** | | | | |
|---|---|---|---|---|
| ***-ның/-нең*** | ***-га/-гә, -ка/-кә*** | ***-дан/-дән, -тан/-тән, -нан/-нән*** | ***-да/-дә, -та/-тә*** | бәйлек, бәйлек сүзләр |
| *Мин* ***әнинең*** | *Мин серемне* ***әнигә*** | *Мин бу хәбәрне* | *Мин шул* ***укытучыда*** | *Ул* ***әнисе белән*** *барам. Мин* ***әнием*** |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| *кайтуын* *көтәм*. | *сөйлим*. | ***әнидән*** *белдем*. | *укыдым*. | ***турында*** *сөйлим*. |

| |
|---|
| Тәмамлыклар җөмләдә үзара **тиңдәшләнеп** килергә мөмкин. Алар **санау интонациясе** һәм **тезүче теркәгечләр** аша бәйләнәләр. |

| |
|---|
| Тәмамлыклар ияртүче сүздән алда да, аннан соң да урнаша ала. Беренче очрак **уңай сүз тәртибе**, икенчесе **кире сүз тәртибе** (**инверсия**) дип атала. |

| ***-ның/-нең*** | |
|---|---|
| **аергыч** | **кыек тәмамлык** |
| исемгә иярә | фигыльгә иярә |
| *Мин әнинең күлмәген юдым*. | *Мин әнинең кайтуын көтәм*. |

| |
|---|
| Иялек килешендәге сүз җөмләдә ике функция үти ала. Ул, исемгә иярсә, **аергыч**, ә фигыльгә иярсә, **кыек тәмамлык** була. |

## ХӘЛЛӘР

| |
|---|
| Эш-хәлнең үтәлү-үтәлмәү урынын белдереп, фигыльне ачыклап килә торган җөмләнең иярчен кисәге **урын хәле** дип атала. |

| |
|---|
| Урын хәле булып юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килешендәге һәм *таба, белән, аша, эчендә, башында, өстендә, артында, аркылы, буйлап* кебек бәйлек һәм бәйлек сүзләр белән килгән **исемнәр**; **урын рәвешләре**, **сорау** һәм **күрсәтү алмашлыклары** килергә мөмкин. |

Урын хәлләре янында бернинди дә тыныш билгеләре куелмый. Калган җиде хәлдән аермалы буларак, урын хәле беркайчан да аерымланмый, чөнки аңа ярым хәбәрлек хас түгел.

| № | ФОРМА | ТӘМАМЛЫК | УРЫН ХӘЛЕ |
|---|---|---|---|
| 1. | юнәлеш килеше | *Мин серемне **әбигә** сөйлим.* | *Мин бүген **әбигә** барам.* |
| 2. | чыгыш килеше | *Мин **әбидән** әкият сөйләттерәм.* | *Кичә мин **әбидән** кайттым.* |
| 3. | урын-вакыт килеше | *Мин **Чулпан Илгизовнада** укыйм.* | ***Әбидә** кунак булу рәхәт.* |
| 4. | бәйлек, бәйлек сүз | *Әлеге яңалыкны без **укытучыбыз аша** белдек.* | *Мин мәктәпкә **парк аша** барам.* |

Юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килешендәге һәм кайбер бәйлек, бәйлек сүзләр белән килгән исемнәр бер очракта тәмамлык, ә икенче очракта урын хәле булып килергә мөмкин. Алар эш-хәлнең объектын яисә үтәүчесен белдерсәләр, **тәмамлык** булалар. Эш-хәлнең үтәлү-үтәлмәү урынын, юнәлешен, чыгыш ноктасын белдерсә, алар **урын хәле** мәгънәсендә кулланылалар.

Эш-хәлнең үтәлү-үтәлмәү вакытын, башлануын, тәмамлануын белдереп, фигыльне ачыклап килә торган җөмләнең иярчен кисәге **вакыт хәле** дип атала.

Вакыт хәлләре **вакыт рәвешләре**, **хәл фигыльнең өченче һәм дүртенче**

| |
|---|
| **төрләре**, **алмашлыклар** һәм **исемнәр** белән белдерелә. |

| ВАКЫТ ХӘЛЕ | | |
|---|---|---|
| | Вакыт хәле ияртүче сүз белән янәшә килә. | Вакыт хәле ияртүче сүз белән янәшә килми. |
| процессны белдерә | *Мин синә мәктәптән кайткач шалтыратырмын.* | *Мин, мәктәптән кайткач, синә шалтыратырмын.* |
| процессны белдерми | *Мин синә бүген шалтыратырмын.* | *Бүген мин синә шалтыратырмын.* |

| |
|---|
| Вакыт хәлләре җөмләдә ияртүче сүз белән янәшә дә, аннан читтә дә урнаша ала. Ул ияртүче сүз белән янәшә килсә, өтер куелмый. Ярым процессны белдереп, ияртүче сүздән еракта торган вакыт хәлләре үзенә ияреп килгән җөмлә кисәкләре белән бергә өтерләр ярдәмендә аерымлана. |

| |
|---|
| Эш-хәлнең ни рәвешле, ничек үтәлү-үтәлмәвен белдереп, фигыльне ачыклап килә торган җөмләнең иярчен кисәге **рәвеш хәле** дип атала.<br>Рәвеш хәлләре **рәвешләр**, **хәл фигыльләр** һәм **исемнәр** белән белдерелә. Рәвеш хәлләре ияртүче фигыльгә хәл фигыльнең беренче (***-ып/-еп***) һәм икенче төр (***-а/-а***) формалары, ***кебек, шикелле, сыман, төсле*** бәйлекләре һәм бәйлек сүзләре , ***-дай/-дәй*** кушымчалары аша ияреләр. |

| РӘВЕШ ХӘЛЕ | | |
|---|---|---|
| | Рәвеш хәле ияртүче сүз белән янәшә килә. | Рәвеш хәле ияртүче сүз белән янәшә килми. |

| | | |
|---|---|---|
| процессны белдерә | *Ул урам буйлап кулларын кесәсенә яшергән килеш бара.* | *Кулларын кесәсенә яшергән килеш, ул урам буйлап бара.* |
| процессны белдерми | *Ул урам буйлап әкрен генә бара.* | *Ул әкрен генә урам буйлап бара.* |

Рәвеш хәлләре җөмләдә ияртүче сүз белән янәшә дә, аннан читтә дә урнаша ала. Ул ияртүче сүз белән янәшә килсә, өтер куелмый. Ярым процессны белдереп, ияртүче сүздән еракта торган рәвеш хәлләре үзенә ияреп килгән җөмлә кисәкләре белән бергә өтерләр ярдәмендә аерымлана.

| ХӘБӘР | АЕРГЫЧ | РӘВЕШ ХӘЛЕ |
|---|---|---|
| иягә ияртә | исемгә ияртә | фигыльгә ияртә |
| *Апам **әнием сыман**.* | ***Йөрәк сыман** яфрак ята.* | *Ул **укыган сыман** утыра.* |

Эш-хәлнең, билгенең күләмен, дәрәҗәсен белдереп, фигыльне, сыйфатны һәм рәвешне ачыклап килә торган җөмләнең иярчен кисәге **күләм хәле** дип атала.

Күләм хәле **күләм-чама рәвешләре, сан белән ачыкланган исемнәр,** кайбер **алмашлыклар** һәм ***кадәр***, ***чаклы***, ***саен***, ***кат*** бәйлекләре аша ияргән сүзләр белән белдерелә. Күләм хәлләре, башка хәлләрдән аермалы буларак, бик сирәк аерымлана.

| ХӘБӘР | АЕРГЫЧ | КҮЛӘМ ХӘЛЕ |
|---|---|---|

| иягә ияртү | исемгә ияртү | сыйфатка, рәвешкә ияртү |
|---|---|---|
| *Көн* ***нинди****?* | ***Нинди*** *кыз килгән безгә?* | ***Нинди*** *матур кыз килгән безгә?!* |

| **УРЫН ХӘЛЕ** | **КҮЛӘМ ХӘЛЕ** | **ВАКЫТ ХӘЛЕ** |
|---|---|---|
| *Мин* ***мәктәптән өйгә*** *кайттым.* | ***Төне буе*** *кар яуды.*<br>*Мин* ***мәктәптән өйгә кадәр*** *җәяү кайттым.* | ***Төнлә*** *кар яуды.* |

| **КҮЛӘМ ХӘЛЕ** | | |
|---|---|---|
| *Без Волгоградка* ***ике көн****,* ***ике төн*** *бардык.* | ***Шундый*** *матур көн!* | *Көн матур* ***шундый****!* |

Эш-хәлнең сәбәбен белдереп, фигыльне ачыклап килә торган җөмләнең иярчен кисәге **сәбәп хәле** дип атала.
Сәбәп хәле **исем, сыйфат фигыль, хәл фигыль** һәм **исем фигыль** белән белдерелә. Алар ияртүче сүзгә юнәлеш килеше кушымчасы ***-га/-гә, -ка/-кә,*** чыгыш килеше кушымчасы ***-дан/-дән, -тан/-тән, -нан/-нән***, ***сәбәпле, аркасында, өчен, күрә*** бәйлекләре һәм бәйлек сүзләре аша ияреләр.

| **СӘБӘП ХӘЛЕ** | | | |
|---|---|---|---|
| *чыгыш килешендәге* | *юнәлеш килешендәге* | *сәбәпле, аркасында, өчен,* | *-ып/-еп, -гач/-гәч* формалы хәл |

| | | | |
|---|---|---|---|
| исемнәр, исем фигыльләр | исемнәр, исемләшкән сыйфат фигыльләр | *күрә* бәйлекләре белән килгән исемнәр, исемләшкән сыйфат фигыльләр | фигыльләр |
| *Бала* ***шатлагыннан*** *җырлап җибәрде*. | *Бала* ***шатланганга*** *җырлап җибәрде*. | *Бала* ***шатланганга күрә*** *җырлап җибәрде*. | *Бала* ***шатлангач*** *җырлап җибәрде*. *Баласының шатлануын* ***күреп***, *әнисе дә куанды*. |

Сәбәп хәлләре җөмләдә ияртүче сүз белән янәшә дә, аннан читтә дә урнаша ала. Ул ияртүче сүз белән янәшә килсә, өтер куелмый. Ярым процессны белдереп, ияртүче сүздән еракта торган сәбәп хәлләре үзенә ияреп килгән җөмлә кисәкләре белән бергә өтерләр ярдәмендә аерымлана.

Эш-хәлнең, хәрәкәтнең максатын белдереп, фигыльне ачыклап килә торган җөмләнең иярчен кисәге **максат хәле** дип атала.

Максат хәле **исем** һәм **фигыль** сүз төркемнәре белән белдерелә. Алар ияртүче сүзгә юнәлеш килеше кушымчасы ***-га/-гә***, ***-ка/-кә***, инфинитив формасы ***-ырга/-ергә***, ***өчен*** бәйлеге һәм ***дип*** бәйлек сүзе аша ияриәләр.

Гадәттә, укучыларга сәбәп һәм максат хәлләрен аеру авыр. Бу очракта син бер үзенчәлекне исеңдә калдыр: **сәбәп хәле** һәрвакыт **үткән заманга**, ә

| |
|---|
| **максат хәле киләчәк заманга** карый**.** Мәсәлән, *Укыганга, мин бишле алдым.* Бала башта укый, аннары бишле ала, ягъни ***укыганга*** – **сәбәп хәле**. *Без, ял итәргә, авылга кайттык.* Башта кайталар, аннары ял итәләр, ягъни ***ял итәргә*** – **максат хәле**. |

| **МАКСАТ ХӘЛЕ** | | |
|---|---|---|
| | Максат хәле иярткүче сүз белән янәшә килә. | Максат хәле иярткүче сүз белән янәшә килми. |
| процессны белдерә | *Китапларны ул илне күбрәк белү өчен укыды.* | *Ул, илне күбрәк белү өчен, китаплар укыды.* |
| процессны белдерми | *Шагыйрь шигырьләрен балалар өчен яза.* | *Шагыйрь балалар өчен шигырьләр яза.* |

| |
|---|
| Максат хәлләре җөмләдә иярткүче сүз белән янәшә дә, аннан читтә дә урнаша ала. Ул иярткүче сүз белән янәшә килсә, өтер куелмый. Ярым процессны белдереп, иярткүче сүздән еракта торган максат хәлләре үзенә ияреп килгән җөмлә кисәкләре белән бергә өтерләр ярдәмендә аерымлана. |

| |
|---|
| Эш-хәлнең, хәрәкәтнең шартын белдереп, фигыльне ачыклап килә торган җөмләнең иярчен кисәге **шарт хәле** дип атала.<br>Шарт хәле **шарт** һәм **хикәя фигыльләр** белән белдерелә. Алар иярткүче сүзгә ***-са/-сә*** формасы, **-мы/-ме** кушымчасы һәм ***икән*** бәйлек сүзе аша ияреләр. |

| **ШАРТ ХӘЛЕ** | | |
|---|---|---|
| | Шарт хәле иярткүче сүз белән янәшә килә. | Шарт хәле иярткүче сүз белән янәшә килми. |

| | | |
|---|---|---|
| процессны белдерә | *Ул китап укыса белә.* | *Китап укыса, ул белә.* |

Шарт хәлләре җөмләдә ияртүче сүз белән янәшә дә, аннан читтә дә урнаша ала. Ул ияртүче сүз белән янәшә килсә, өтер куелмый. Ияртүче сүздән ерак торган шарт хәлләре үзенә ияреп килгән җөмлә кисәкләре белән бергә өтерләр ярдәмендә аерымлана.

Җөмләдә көтелгән эш яки хәлнең киресен белдереп, фигыльгә ияреп килгән иярчен кисәк **кире хәл** дип атала.
Кире хәл ияртүче сүзгә шарт фигыль формасы белән бергә ***да/дә, та/тә*** кисәкчәсе һәм ***карамастан*** бәйлек сүзе ярдәмендә иярә. Хәл фигыль формасы ***-ып/-еп/-п*** белән бергә ***да/дә, та/тә*** кисәкчәләре.
Кире хәл ияртүче кисәктән ераклашканда, өтерләр ярдәмендә **аерымлана**.

| Рәвеш хәле | Сәбәп хәле | Максат хәле |
|---|---|---|
| *Марат бүлмәдән* ***йөгереп*** *чыгып китте.* | *Марат укытучыны* ***күреп*** *туктап калды.* | *Марат укытучыны* ***эзләп*** *чыгып китте.* |

Җөмләдә ияртүче сүздән соң килеп, аның мәгънәсенә өстәмә ачыклык бирә торган җөмләнең иярчен кисәге **аныклагыч** (уточнение) дип атала. Аныклагыч ияреп килгән кисәк **аныкланмыш** дип атала. Аныклагычка тоташтан ике дулкынлы сызык ( ______ ) сызыла.

| **АНЫКЛАГЫЧ** | | |
|---|---|---|
| **җыйнак** | **җәенке** | **тиңдәш** |

| | | |
|---|---|---|
| Без, **кызлар**, 8 нче сыйныфта укыйбыз. | Без, **тырыш кызлар**, 8 нче сыйныфта укыйбыз. | Без,ягъни **Алсу**, **Ләйсән** һәм **Айгөл,** 8 нче сыйныфта укыйбыз. |

| |
|---|
| Аныклагычлар **җыйнак** (бер сүз белән генә), **җәенке** (сүзләр тезмәсе белән) була ала. Алар **тиңдәшләнеп** тә килергә мөмкин. Аныклагычлар аныкланмышка **аныклау интонациясе** һәм ***ягъни***, ***икенче төрле әйткәндә***, ***аеруча***, ***бигрәк тә*** кебек теркәгечләр ярдәмендә ияргәләр. Теркәгечләрнең астына сызылмый!<br>Аныклагычлар аныкланмыштан тыныш билгеләре белән аерымланалар. |

| **АНЫКЛАГЫЛАР ЯНЫНДА ТЫНЫШ БИЛГЕЛӘРЕ** | | |
|---|---|---|
| аныкланмыш | тыныш билгесе | мисал |
| Алмашлык, рәвеш сүз төркемнәре; урын һәм вакыт хәлләре | **,**<br>**(ӨТЕР)** | Алар**, 8 нче сыйныф укучылары,** сәяхәткә киттеләр.<br>Югарыда**, тау башында,** агач үсә.<br>Агач югарыда**, тау башында** үсә. |
| Исем сүз төркеме | **-**<br>**(СЫЗЫК)** | Балалар – **8 нче сыйныф укучылары** – сәяхәткә киттеләр.<br>Сәяхәткә балалар – **8 нче сыйныф укучылары** киттеләр. |
| Хәбәр | **:**<br>**(ИКЕ НОКТА)** | Концертта 8 нче сыйныф укучылары чыгыш ясадылар**: җырладылар, биеделәр**. |
| Искәрмә характерында булса | **( )**<br>**(ҖӘЯЛӘР)** | 8 нче сыйныф укучылары сәяхәткә **(походка)** киттеләр. |

| |
|---|
| Аныклагычлар **өтер**, **сызык**, **ике нокта** һәм **җәяләр** ярдәмендә аерымлана. |

Ул анықланмышка теркәгечләр аша иярсә, әлеге бәйләүче чаралар алдыннан һәрвакыт **өтер** куела. Аныклагыч хәбәр белән янәшә килсә, өтер яисә сызык аның алдыннан гына куела.

Аныклагычлар һәрвакыт анықланмыштан соң, ягъни ияртүче сүздән соң киләләр. Алар арасында кире сүз тәртибе (инверсия) булмый.

Җөмләдә сөйләм төбәлгән затны, әйберне белдергән модаль җөмлә кисәге **эндәш сүз** дип атала. Алар җөмләнең теләсә кайсы урынында килә алалар.

| **ЭНДӘШ СҮЗЛӘР** | | | |
|---|---|---|---|
| кешеләргә | кош-кортларга, хайваннарга | табигать күренешләренә | абстракт төшенчәләргә |
| *Алсу, дәфтәреңне тапшыр.* | *Песнәкләр, җимлегемә килегез.* | *Кар, яумый тор!* | *Туган илем, мин сине яратам!* |

Җөмлә башында килгән эндәш сүздән соң зуррак, җөмлә ахырында урнашкан эндәш сүз алдыннан кыскарак пауза ясала. Эндәш сүз башка җөмлә кисәкләреннән **өтер** белән аерыла. Көчле тойгы белән әйтелгән очракта, аннан соң **өндәү билгесе** дә кулырга мөмкин.

Җөмләдә эндәш сүзләр **тиңдәшләнеп** килә ала. Алар, гадәттә, санау интонациясе аша тезелеп китәләр. Автор көчле тойгы белән әйткәндә, бер үк эндәш сүзне кабатлап та бирә. Эндәш сүзләр **җыйнак** та, **җәенке** дә булырга мөмкин.

Эндәш сүзләр янында ***әй, и*** кебек ымлыклар килергә мөмкин. Ул очракта

| |
|---|
| алар арсына өтер куелмый. Эндәш сүзле җөмләдә зат алмашлыгы белән белдерелгән ия күп очракта әйтелми. Исегездә калдырыгыз: зат алмашлыгы эндәш сүз булмый! |

| **КЕШЕЛӘРГӘ АТАП ӘЙТЕЛГӘЕН ЭНДӘШ СҮЗЛӘР** | | | |
|---|---|---|---|
| кешенең исеме, фамилиясе, әтисенең исеме | кешенең һөнәре белән бәйле исемнәр | рәсми кешеләргә, дусларга, туганнарга атап әйтелгән сүзләр | иркәләп, яратып эндәшү өчен кулланыла торган сүзләр |
| *Алсу Илгизовна, керегә ярыймы?* | *Укучылар, дәрескә әзерләнегез.* | *Дустым, миңа яңа теманы аңлат әле.* | *Җимешем, йокла инде!* |

| |
|---|
| Сөйләүченең җөмләдәге фикергә мөнәсәбәтен белдерә торган модаль кисәк **кереш сүз** дип атала. Алар **җыйнак** һәм **җәенке** булалар.<br>Кереш сүзләр җөмлә башында да, уртасында да, ахырында да килә ала. Алар һәрвакыт **өтер** белән аерыла. |

| **КЕРЕШ СҮЗЛӘР** | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **ышану, раслау** | **шикләнү, икеләнү** | **үтенү** | **фикер чыганагы** | **фикер нәтиҗәсе, йомгагы** | **фикер тәртибе** | **фикергә бәйләнгән төрле тойгы** |
| *дөрес, әлбәттә, һичшиксез, чынлап та, билгеле* | *ахры, мөгаен, никтер, ни өчендер, бәлки, ихтимал* | *зинһар* | *минемчә, алар фикеренчә* | *димәк, кыскасы, гомумән, киресенчә, бер сүз белән әйткәндә* | *беренчедән, икенчедән, ниһаять* | *бәхеткә, бәхетсезлеккә, кызганычка, имеш, ичмасам* |
| ***Бүген,*** | ***Мөгаен,*** | *Улым,* | *Бүген* | ***Димәк,*** | *Дәрес* | ***Ичмасам,*** |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| *һичшиксез, чаңгыда шуам.* | *көн салкын.* | *кайт, **зинһар**!* | *көн салкын, **минемчә**.* | *бүген дәрес булмый.* | *тәмам, **ниһаять**.* | *кар да яумый.* |

| **ГРАММАТИК АНАЛИЗ ТӨРЛӘРЕ** | | | |
|---|---|---|---|
| **Морфологик анализ** | **Синтаксик анализ** | **Морфологик-синтаксик анализ** | **Синтаксик-морфологик анализ** |
| *Без ап-ак **кышны** яратабыз.* | | | |
| ***Кышны** – исем, уртаклык, төшем килешендә, тартым белән төрләнмәгән, берлек санда.* | ***Кышны** – туры тәмамлык.* | ***Кышны** – исем, уртаклык, төшем килешендә, тартым белән төрләнмәгән, берлек санда; җөмләдә тәмамлык булып килгән.* | ***Кышны** – туры тәмамлык; исем белән белдерелгән.* |

| **ӘЙТҮ МАКСАТЫ ЯГЫННАН ҖӨМЛӘ ТӨРЛӘРЕ** | | |
|---|---|---|
| **Хикәя** | **Сорау** | **Боерык** |
| *Бүген чаңгы ярышында катнашабыз.* | *Бүген чаңгы ярышында катнашабызмы?* | *Бүген чаңгы ярышында катнашыгыз!* |
| Тойгы өстәлә | | |
| **Тойгылы хикәя** | **Тойгылы сорау** | **Тойгылы боерык** |

| | | |
|---|---|---|
| *Ура! Бүген чаңгы ярышында катнашабыз!!!* | *Бүген чаңгы ярышында ничек кенә катнаштык?!* | *Бүген чаңгы ярышында катнашыгыз, зинһар!* |

Без, сөйләшкәндә, төрле максат куябыз: я нәрсә турында булса да хәбәр итәбез, я нәрсә турындадыр беләсебез килә, я ниндидер эш кушабыз, үтенәбез һ.б. Шул яктан җөмләләр өч төргә бүленә: **хикәя**, **сорау** һәм **боерык**. Алар төрле интонация белән әйтелә. Үзебезнең тойгыларыбызны белдергән очракта, алар **тойгылы җөмләгә** әйләнә.

Эш-хәлләр, күренешләр турында хәбәр итә торган җөмлә **хикәя җөмлә** дип атала. Хикәя җөмлә тыныч тавыш белән әйтелә, аның ахырында **нокта** куела.

Теге яки бу әйбер турында сорауны белдергән җөмлә **сорау җөмлә** дип атала. Сорау я тыңлаучыга, я сөйләүченең үзенә бирелә. Сорау җөмләдән соң һәрвакыт **сорау** (**?**) билгесе куела. Сорау җөмлә **сорау алмашлыклары**, ***-мы/-ме (-мыни/-мени, микән***) **сорау кисәкчәсе** һәм **сорау интонацисе** белән белдерелә.

Эшкә кушуны, боеруны һәм үтенүне белдергән җөмлә **боерык җөмлә** дип атала. Ул югары тон һәм югарырак тавыш белән әйтелә. Боерык җөмләнең хәбәре, күбесенчә, боерык фигыль белән белдерелә. Көчле тойгы белән әйтелгән боерык җөмләдән соң **өндәү** (**!**), тыныч тавыш белән әйтелгән очракта, **нокта** (**.**) куела.

Хикәя, сорау һәм боерык җөмләләр көчле тойгы (эмоция) белән әйтелгәндә **тойгылы җөмләгә** (восклицательное предложение) әйләнәләр. Бу җөмләләрдә соклану, шатлану, курку, үкенү, теләк, шикләнү кебек тойгылар

(хисләр) белдерелә. Тойгылы җөмлә һәрвакыт күтәренке тавыш белән әйтелә, җөмлә ахырына һәрвакыт **өндәү (!)** билгесе куела.

Тойгылы җөмлә барлыкка килүдә **көчле интонация**, **сорау алмашлыклары**, **кире сүз тәртибе**, **кисәкчәләр** һәм **ымлыклар**, бер үк сүзне **кабатлаулар** мөһим роль уйный.

Эш-хәрәкәтне раслау яки кире кагуга карап, җөмләләр **раслау** һәм **инкяр** җөмләләргә бүленә. Раслау җөмлә затларның, предмет-күренешләрнең, эшнең, билгенең булуын раслый. Инкяр җөмлә нәрсәне дә булса инкяр итә.

Инкяр җөмлә ***-ма/-мә, -мый/-ми, -сыз/-сез*** кушымчалары, **юк**, **түгел** сүзләре ярдәмендә барлыкка килә.

Баш кисәкләрдән, ягъни ия белән хәбәрдән генә торган җөмлә **җыйнак җөмлә** дип атала. Баш кисәкләрдән тыш иярчен яисә модаль җөмлә кисәкләре кулланылган булса, ул **җәенке җөмлә** дип атала.

Еш кына җөмләдә ияләр яисә хәбәрләр тиңдәшләнеп килә. Андый җөмләләр дә, иярчен кисәкләр файдаланылмаган булса, **җыйнак җөмлә** дип атала.

| **ҖӨМЛӘ** | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **җыйнак җөмлә** | | | **җәенке җөмлә** | | |
| *Мин җырлыйм.* | *Кыш.* | *Укыйм.* | *Мин китап укыйм.* | *Улым, укы!* | *Укы, зинһар!* |

Җыйнак җөмләдә баш кисәкләрнең икесе дә, яисә берсе генә дә булырга мөмкин. Җәенке җөмлә иярчен кисәкләр белән генә түгел, эндәш һәм кереш сүзләр дә өстәлеп ясала.

Баш кисәкләрнең санына карап, җөмләләр **ике составлы** һәм **бер составлы** җөмләләргә бүленә.

| **ҖӨМЛӘ** | |
|---|---|
| **Ике составлы җөмлә** | **Бер составлы җөмлә** |
| *Мин китап укыйм. Китап укыйм (мин).* | *Миңа мәктәпкә барырга кирәк. Төн. Бүлмәдә утырырлык түгел.* |

Ике составлы җөмләдә ия дә, хәбәр дә була. Берсе булмаган очракта аны куеп карап була. Бер составлы җөмләдә бер генә баш кисәк була, икенчесен куеп карап булмый.

Бер составлы җөмлә ике төргә бүленә. Җөмләнең иясе генә булып, хәбәрне куеп карап булмаса, ул **бер составлы исем җөмлә** дип атала. Җөмләнең хәбәре генә булып, иясен куеп карап булмаса, ул **бер составлы фигыль җөмлә** була.

Баш кисәкләрдән иясе генә булган җөмлә **бер составлы исем җөмлә** дип атала. Бер составлы исем җөмләләрнең баш кисәге **исем**, **сыйфат**, **рәвеш** һәм **исем фигыль** белән белдерелә. Алар күренешләрнең исемнәрен, әйбернең билгесен атый.

Баш кисәкләрдән хәбәре генә булган һәм ияне куеп карап булмаган җөмлә **бер составлы фигыль җөмлә** дип атала.
Гадәттә, хәбәре генә бирелгән мәкальләргә “син” дигән ияне куеп карап була. Ләкин әлеге әйтемнәр безнең барыбызга да караганга күрә, әлеге төр җөмләләр дә бер составлы фигыль җөмлә дип атала.

БЕР СОСТАВЛЫ ФИГЫЛЬ ҖӨМЛӘ

| **билгеле үтәүчеле** | **билгесез үтәүчеле** | **гомум үтәүчеле** | **үтәүчесез** |
|---|---|---|---|
| эш башкаручыны җөмләдән, контексттан белә алабыз. | эш башкаручының кем икәнен белеп булмый. | эш барлык кешегә дә карый | башкаручы булмый, эш үзеннән үзе үтәлә кебек тоела |
| *Урамда музыка уйнаталар.* | *Бүген никтер арылды.* | *Урамга чыгарлык түгел – көчле җил исә.* | *Аякны көзән җыера.* |

Җөмлә аваз ияртеменнән, хәбәрлек сүздән, ымлыктан яисә кисәкчәдән генә торса, ул **сүз җөмлә** дип атала. Әлеге сүзләр җөмлә кисәге түгел, аларның асларына сызылмый. Аларга башка сүз ияреп килә алмый.

Җөмләнең мәгънәсе аңлашылсын өчен кирәк булган җөмлә кисәкләре барысы да кулланылса, ул **тулы җөмлә** дип атала. Алдагы җөмләләрдән белеп була торган бер яки берничә җөмлә кисәге төшеп калган җөмлә **ким җөмлә** була.

Ике яки берничә гади җөмләдән торган җөмлә **кушма җөмлә** дип атала. Кушма җөмлә эчендәге гади җөмләләр, җөмлә кисәкләре кебек үк, я бер-берсе белән тезелеп, я бер-берсенә ияреп килә.

Ияләре яисә хәбәрләре тиңдәшләнеп килгән җөмлә гади җөмлә була.

Компонентлары үзара тезү юлы белән бәйләнгән җөмлә **тезмә кушма җөмлә** дип атала.

## ТЕЗМӘ КУШМА ҖӨМЛӘ

| Теркәгечсез тезмә кушма җөмлә | Теркәгечле тезмә кушма җөмлә |
|---|---|
| *(1)Бүгенге концертта Айгөл җырлый, (2)Марат шигырь сөйли.* | *(1)Бүгенге концертта Айгөл җырлый, (2)ә Марат шигырь сөйли.* |

Тезмә кушма җөмләнең компонентлары үзара **интонация** яисә **теркәгеч** аша бәйләнә.

Компонентлары санау яисә каршы кую интонациясе аша бәйләнгән кушма җөмлә **теркәгечсез тезмә кушма җөмлә** дип атала. Теркәгечсез тезмә кушма җөмлә компонентлары санау яки каршы кую интонациясе аша бәйләнгән очракта, гади җөмләләр арасына **өтер** ( **,** ), кискен каршы кую интонациясе аша бәйләнгән гади җөмләләр арасына **сызык** ( **–** ) куела.

Компонентлары тезүче теркәгечләр аша бәйләнгән кушма җөмлә **теркәгечле тезмә кушма җөмлә** дип атала.

| **ТЕРКӘГЕЧЛЕ ТЕЗМӘ КУШМА ҖӨМЛӘ** | | |
|---|---|---|
| җыючы теркәгечләр | каршы куючы теркәгечләр | бүлүче теркәгечләр |
| *һәм, да, дә, да/да, ни/ни, янә/янә* | *ләкин, ә, әмма, тик* | *я/я, яки, яисә, әле/әле, әллә/әллә* |
| *(1)Көз җитте, (2)һәм кошлар җылы якка киттеләр.* | *(1)Көз җитте, (2)ләкин көннәр җылы.* | *(1)Көз көне әле яңгыр ява, (2)әле кар ява.* |

Теркәгечле тезмә кушма җөмлә компонентлары арасына **өтер** ( **,** ) куела.

Өч һәм аннан да күбрәк гади җөмләләр үзара тезүле бәйләнештә килсәләр, **күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә** барлыкка килә.

| |
|---|
| Бер компоненты икенчесенә ияреп килгән кушма җөмлә **иярченле кушма җөмлә** дип атала. Ияреп килгәне – **иярчен җөмлә**, ияртеп килгәне **баш җөмлә** була. |

| **ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘ** | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| төзелеше ягыннан | | | | | | | | | | | | |
| **АНАЛИТИК** | | | | | | **СИНТЕТИК** | | | | | | |
| мәгънәсе ягыннан | | | | | | | | | | | | |
| **ия** | **хәбәр** | **тәмамлык** | **аергыч** | **вакыт** | **урын** | **рәвеш** | **күләм** | **сәбәп** | **максат** | **шарт** | **кире** | **аныклагыч** |

**СИНТЕТИК ҺӘМ АНАЛИТИК ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘЛӘРНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ, АЛАРНЫҢ СИНОНИМЛЫГЫ**

| **СИНТЕТИК ЧАРАЛАР** | | |
|---|---|---|
| кушымчалар, фигыль формалары | бәйлек, бәйлек сүзләр | янәшә тору |
| (1)*Өй каршыбызда* (2)***яфраклары саргайган*** (1)*каен үсә*. | (1)***Яфраклары саргаю белән,*** (2)*өй каршыбыздагы каен моңсулана башлый*. | (1)*Өй каршыбызда* (2)***яфраклары сары*** (1)*каен үсә*. |

| **АНАЛИТИК ЧАРАЛАР** | | |
|---|---|---|
| мөнәсәбәтле сүзләр (*шул, шуны, шунда, шул чакта, нигә – шул сәбәпле, ничек – шулай,* ...) | ияртүче теркәгечләр (*чөнки, гүя, гүяки, әйтерсең*) | күтәрү интонациясе |
| (1)***Шул*** *билгеле*: (2)*һәркем* | (1)*Укытучы мактады*, | (1)*Мин беләм*: (2)*хәзер* |

| | | |
|---|---|---|
| *тырышырга тиеш*. (1)*Син* ***кайчан*** *чакырасың*, (2)*мин* ***шул вакытта*** *киләм*. | (2)***чөнки*** *мин шигырьне сәнгатьле итеп укыдым*. | *дәрес башлана*. |

Синтетик иярчен җөмләләр баш җөмләгә **кушымчалар, фигыль формалары**, **бәйлек**, **бәйлек сүзләр** һәм **янәшә тору** чаралары ярдәмендә ияртә. Синтетик чаралар һәрвакыт иярчен җөмләнең хәбәре составында киләләр, шуңа күрә алар ике компонент чиген билгелиләр!
Аналитик иярчен җөмлә баш җөмләгә **мөнәсәбәтле сүзләр**, **ияртүче теркәгечләр** һәм **күтәрү интонациясе** аша ияртә. Аналитик чаралар иярчен җөмләнең хәбәре составында булмый һәм ике компонент чиген дә билгели алмый!

Синтетик иярчен җөмлә баш җөмләдән **алда** да, аның **уртасында** да килә ала. Аналитик иярчен җөмлә баш җөмләдән **алда** һәм **аннан соң** урнашырга мөмкин.

| синтетик иярчен җөмлә | гади җөмлә кисәге | аналитик иярчен җөмлә |
|---|---|---|
| (1)*Мин*, (2)***әни кайткач,*** (1)*сиңа шалтыратырмын*. | *Мин*, ***кайткач***, *сиңа шалтыратырмын*. | (1)***Әни кайчан кайта,*** (2)*мин сиңа шул вакытта шалтыратырмын*. |

Синтетик иярчен җөмлә гади иярчен кисәккә бик нык охшаган (бәйләнү чаралары, җөмләдәге урыннары, интонация, тыныш билгесе). Аерма шунда гына: иярчен җөмләдә ия белән хәбәр була.

Синтетик иярчен җөмлә төрки телләрнең үзенчәлеге булып санала,

андый төр җөмләләр рус телендә юк. Аналитик иярчен җөмләләр татар телендә дә, рус телендә дә бар.

Татар телендә бер иярчен җөмләне синоним җөмләләргә үзгәртеп була. Бу очракта өч кагыйдәне истә тотарга кирәк:

1. Үзгәртү вакытында кушма җөмлә саклана.

2 Җөмләдәге сүзләр төшеп калмый һәм яңа сүз дә өстәлми, ә бары тик бәйләүче чара гына үзгәрә.

3. Иярчен җөмләнең мәгънәсе сакланырга тиеш.

| **ИЯРЧЕНЛЕ КУШМА ҖӨМЛӘ** | |
|---|---|
| **синтетик иярчен рәвеш җөмлә** | **аналитик иярчен рәвеш җөмлә** |
| (1)*Марат*, (2)***корт чаккандай***, (1)*урыныннан сикереп торды*.<br>(1)*Марат*, (2)***корт чаккан төсле***, (1)*урынынан сикереп торды*.<br>(1)*Марат*, (2)***корт чаккан шикелле***, (1)*урыныннан сикереп торды*. | (1)***Ничек корт чага***, (2)*Марат шулай урыныннан сикереп торды*.<br>(1)*Марат урыныннан сикереп торды*, (2)***әйтерсең корт чакты***.<br>(1)*Марат урыныннан сикереп торды*, (2)***гүя корт чакты***. |
| **ТҮБӘНДӘГЕЧӘ ҮЗГӘРТЕРГӘ ЯРАМЫЙ:** | |
| (1)*Марат*, (2)***корт чаккач***, (1)*урыныннан сикереп торды*. | (1)*Марат урыныннан сикереп торды*, (2)***чөнки корт чакты***. |

| **МӨНӘСӘБӘТЛЕ СҮЗЛӘРНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ** |
|---|
| 1. Мөнәсәбәтле сүзләр булып, билгеләү алмашлыклары һәм бер саны килә: ***шул, шунда, шуны, шулай, шулай булса, шул турыда, шул сәбәпле, шул максаттан, шуңа карамастан, шул вакытта, шундый итеп, бер, ...*** |

| |
|---|
| 2. Мөнәсәбәтле сүзләр һәрвакыт **баш җөмләдә** килә: (1)*Әнием кайтты*, (2)*шуннан соң без кичке ашны ашадык*. |
| 3. Мөнәсәбәтле сүзләр – **җөмлә кисәге**. Тулы синтаксик анализ вакытында, аларның асларына сызыла: (1)*Әнием кайтты*, (2)*шуннан соң без кичке ашны ашадык*. |
| 4. Мөнәсәбәтле сүзләр нинди җөмлә кисәге булса, иярчен җөмлә нәкъ шундый җөмлә була: (1)*Әнием кайтты*, (2)*шуннан соң без кичке ашны ашадык*. |
| 5. Мөнәсәбәтле сүз урынына иярчен җөмләне куеп карап була: (1)*Әнием кайткач*, (2)*без кичке ашны ашадык*. |
| 6. Мөнәсәбәтле сүзләр сорау алмашлыклары белән белдерелгән сүзләр белән парланып та килә алалар: ***кем – шул, кайда – шунда, кайчан – шул вакытта, нихәтле – шулхәтле, кемне – шуны, ...*** : (1)***Кайчан*** *әнием кайта*, (2)***шул вакытта*** *без кичке ашны ашыйбыз*. |

| **ИЯРТҮЧЕ ТЕРКӘГЕЧЛӘРНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ** |
|---|
| 1. Ияртүче теркәгечләр: ***чөнки, әгәр, гүя, гүяки, әйтерсең, ягъни, ...*** |
| 2. Ияртүче теркәгечләр һәрвакыт **иярчен җөмләдә** килә: (1)*Без урамга чыкмыйбыз*, (2)*чөнки яңгыр ява*. |
| 3. Ияртүче теркәгечләр – **җөмлә кисәге түгел**. Тулы синтаксик анализ вакытында, аларның асларына сызылмый: (1)*Без урамга чыкмыйбыз*, (2)*чөнки яңгыр ява*. |
| 4. Ияртүче теркәгечләргә генә карап, иярчен җөмләнең мәгънә ягыннан төрен төгәл билгеләп булмый. |
| 5. Ияртүче теркәгеч урынына үзеннән алда яки үзеннән соң килгән җөмләне куеп карап булмый. |

| СИНТЕТИК ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘ | | |
|---|---|---|
| **өтер** (**,**) | тыныш билгесе куелмый | **өтер** (**,**) |
| Синтетик иярчен җөмлә баш җөмләдәге ияртүче сүздән ераклашкан | Синтетик иярчен аергыч, тәмамлык, урын җөмләләр | Синтетик иярчен тәмамлык җөмлә баш җөмләгә ***дип*** бәйлек сүз ярдәмендә ияргән |
| *(1)**Күз җиткәч**, (2)көннәр салкынайды.*<br>*(1)Көннәр (2)**күз җиткәч** (1)салкынайды.* | *(1)**Без барасы** (2)юллар ерак.*<br>*(1)Мин (2)**әнием кайтканны** (1)көтәм.*<br>*(1)**Балалар җыелган җирдә** (2)тавыш тынмый.* | *(1)**Син матур биисең дип**, (2)мин уйламаган идем.*<br>*(1)**Син матур биисең дип** (2)уйламаган идем мин.* |

| АНАЛИТИК ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘ | |
|---|---|
| **өтер** (**,**) | **ике нокта** (**:**) |
| Парлы мөнәсәбәтле сүзләр: *(1)**Кем** эшләми**,** (2)**шул** ашамый*. (Мәкаль) | Көттерү интонациясе: *(1)Беләм**:** (2)бүген көн салкын*. |
| Мөнәсәбәтле сүзе булган баш җөмлә иярчен җөмләдән соң килә: *(1)Болытлар җыелган**,** (2)**шул яктан** җил исә*. | |
| Ияртүче теркәгечләр алдыннан: *(1)Гөлләрем үсә**,** (2)**чөнки** мин аларга су сибәм*. | |

| |
|---|
| Баш җөмлә белән синтетик иярчен җөмлә арасына **өтер** (**,**) генә куела ала.<br>Баш җөмлә белән аналитик иярчен җөмлә арасына **өтер** (**,**) һәм **ике нокта** (**:**) куелырга мөмкин. |

**Иярчен ия җөмлә** баш җөмләнең иясе урынында килә, яисә баш җөмләдәге мөнәсәбәтле сүз белән белдерелгән ияне ачыклый. **Иярчен ия җөмлә** баш җөмләгә һәм **синтетик** (сыйфат фигыль формалары, янәшә тору), һәм **аналитик** (мөнәсәбәтле сүзләр, көттерү интонациясе) чаралар ярдәмендә иярә.

**Иярчен хәбәр җөмлә** баш җөмләнең хәбәре урынында килә, яисә баш җөмләдәге мөнәсәбәтле сүз белән белдерелгән хәбәрне ачыклый. **Иярчен хәбәр җөмлә** баш җөмләгә бары тик **аналитик** (мөнәсәбәтле сүзләр, көттерү интонациясе) чаралар ярдәмендә иярә.

| **ИЯРЧЕН ИЯ ҖӨМЛӘ** | | | |
|---|---|---|---|
| Синтетик чаралар | | Аналитик чаралар | |
| сыйфат фигыль формасы (***-ган/-гән, -кан/-кән, -ачак/-әчәк, -асы/-әсе***) | янәшә тору | мөнәсәбәтле сүзләр: ***шул, шунысы, кем – шул, кемнең – шул, нәрсә – шул*** | көттерү интонациясе |
| (1)***Теләге булган*** (2)*тик тормас*. (Мәкаль) | (1)***Теләге бар*** (2)*тик тормас*. | (1)***Кемнең теләге бар***, (2)*шул тик тормас*. | (1)*Билгеле*: (2)***бүген көн җылы***. |

| **ИЯРЧЕН ХӘБӘР ҖӨМЛӘ** | |
|---|---|
| Аналитик чаралар | |
| мөнәсәбәтле сүзләр: ***шул, шунда, шундый, кем – шуңа, кем – шул, нинди – шундый, ни кадәр – шул кадәр, кайда – шунда*** | көттерү интонациясе |
| (1)***Энә кайда***, (2)*җеп шунда*. (Мәкаль) | (1)*Мөһиме*: (2)***укучылар дәрескә әзер***. |

| |
|---|
| **Иярчен тәмамлык җөмлә** баш җөмләнең тәмамлыгы урынында килә, яисә баш җөмләдәге мөнәсәбәтле сүз белән белдерелгән тәмамлыкны ачыклый. Иярчен тәмамлык җөмлә баш җөмләгә һәм **синтетик** (төшем килеше кушымчасы *-ны/-не*, *дип* бәйлек сүзе), һәм **аналитик** (мөнәсәбәтле сүзләр, күтәрү интонациясе) чаралар ярдәмендә ияртә. |

| **ИЯРЧЕН ТӘМАМЛЫК ҖӨМЛӘ** | | | |
|---|---|---|---|
| Синтетик чаралар | | Аналитик чаралар | |
| төшем килеше (-***ны/-не***) һәм юнәлеш килеше (***-га/-гә, -ка/-кә***) кушымчалары | ***дип*** бәйлек сүзе | мөнәсәбәтле сүзләр: ***шуны***, ***шул турыда***, ***кемне – шуны*** | күтәрү интонациясе |
| *(1)Мин (2)**әнием җырлаганны** (1)тыңлап торам*. | *(1)**Әнием матур җырлый дип** (2)уйламаган идем мин*. | *(1)Мин шуны беләм: (2)**әнием матур җырлый***. | *(1)Мин беләм: (2)**әнием матур җырлый***. |

| |
|---|
| **Иярчен аергыч җөмлә** баш җөмләнең аергычы урынында килә, яисә баш җөмләдәге мөнәсәбәтле сүз белән белдерелгән аергычны ачыклый. Иярчен аергыч җөмлә һәрвакыт баш җөмләдәге исем белән белдерелгән сүзгә ияреп, аны ачыклап килә. Иярчен аергыч җөмлә баш җөмләгә һәм **синтетик** (иялек килеше кушымчасы *-ның/-нең*, сыйфат фигыль формалары һәм янәшә тору), һәм **аналитик** (мөнәсәбәтле сүзләр) чаралар ярдәмендә ияртә. |

| **ИЯРЧЕН АЕРГЫЧ ҖӨМЛӘ** | |
|---|---|
| Синтетик чаралар | Аналитик чаралар |

| | | | |
|---|---|---|---|
| иялек килеше кушымчасы -***ның/-нең*** | сыйфат фигыль формалары (-***ган/-гән, -кан/-кән, -асы/-әсе, -а торган/-ә торган, -учы/-үче, -ыр/-ер***) | янәшә тору | мөнәсәбәтле сүзләр: ***шул, шундый, шуның, бер, кем – шуның, кем – шул, кемнең – шуның*** |
| (1)***Теле татлының*** (2)*дусты күп*. (Мәкаль) | (1)***Үзең эчәсе*** (2)*коега түкермә*. (Мәкаль) | (1)***Күзе ачык*** (2)*кеше ач калмый*. (Мәкаль) | (1)***Кемнең хезмәте бар***, (2)*шуның хөрмәте бар*. (Мәкаль) |

| |
|---|
| **Иярчен вакыт җөмлә** баш җөмләнең вакыт хәле урынында килә, яисә баш җөмләдәге мөнәсәбәтле сүз белән белдерелгән вакыт хәлен ачыклый. Иярчен вакыт җөмлә баш җөмләгә һәм **синтетик** (исем фигыль формасына юнәлеш килеше кушымчасы, сыйфат фигыль формасына урын-вакыт килеше кушымчасы, хәл фигыль формалары, *вакытта, соң, чакта, белән* бәйлек һәм бәйлек сүзләре), һәм **аналитик** (мөнәсәбәтле сүзләр) чаралар ярдәмендә ияртә. |

| **ИЯРЧЕН ВАКЫТ ҖӨМЛӘ** | | |
|---|---|---|
| Синтетик чаралар | | Аналитик чаралар |
| исем фигыль формасы + юнәлеш килеше кушымчасы (-***уга/-үгә***), сыйфат фигыль формасы + урын-вакыт | бәйлек һәм бәйлек сүзләр (***вакытта, чакта, арада, соң, белән***) | мөнәсәбәтле сүзләр: ***шул чакта, шул вакытта, шуннан соң, шуңа кадәр, кайчан – шунда, кайчан – шул*** |

| | | |
|---|---|---|
| килеше кушымчасы (-***ганда/-гәндә, -канда/-кәндә***) һәм хәл фигыль формалары (***-ып/-еп, -гач/-гәч, -кач/-кәч***) | | ***вакытта, кайчан – шул чакта*** |
| *(1)Укытучы аңлатканда, (2)укучылар аны игътибар белән тыңлыйлар.* | *(1)Укытучы аңлаткан вакытта, (2)укучылар аны игътибар белән тыңлыйлар.* | *(1)Укытучы кайчан аңлата, (2)укучылар аны шул вакытта игътибар белә тыңлыйлар.* |

**Иярчен урын җөмлә** баш җөмләнең урын хәле урынында килә, яисә баш җөмләдәге мөнәсәбәтле сүз белән белдерелгән урын хәлен ачыклый. **Иярчен урын җөмлә** баш җөмләгә һәм **синтетик** (*урынга, урында, җирдә, яктан* бәйлек һәм бәйлек сүзләре), һәм **аналитик** (мөнәсәбәтле сүзләр) чаралар ярдәмендә иярә.

| **ИЯРЧЕН УРЫН ҖӨМЛӘ** | |
|---|---|
| Синтетик чаралар | Аналитик чаралар |
| бәйлек һәм бәйлек сүзләр (***урынга, урында, җирдә, яктан, якта***) | мөнәсәбәтле сүзләр: ***кайда – шунда, кая – шунда, кайда – шул җирдә*** |
| *(1)**Җил искән яктан** (2)болыт килә.* | *(1)**Җил каян исә**, (2)болыт шул яктан килә.* |

| Иярчен аергыч җөмлә | Иярчен урын җөмлә |
|---|---|
| ***җирдә*** – исем (почва) | ***җирдә*** – бәйлек сүз (место) |
| *(1)**Ашлама кергән** (2)җирдә уңыш әйбәт була.* | *(1)**Халык җыелган җирдә** (2)сүз күп була.* |

| |
|---|
| **Иярчен рәвеш җөмлә** баш җөмләнең рәвеш хәле урынында килә, яисә баш җөмләдәге мөнәсәбәтле сүз белән белдерелгән рәвеш хәлен ачыклый. Иярчен рәвеш җөмлә баш җөмләгә һәм **синтетик** (рәвеш ясагыч кушымчалар, *кебек, шикелле, сыман, төсле, итеп* бәйлек һәм бәйлек сүзләре), һәм **аналитик** (мөнәсәбәтле сүзләр, теркәгеч һәм теркәгеч сүзләр) чаралар ярдәмендә иярә. |

| **ИЯРЧЕН РӘВЕШ ҖӨМЛӘ** | | | |
|---|---|---|---|
| Синтетик чаралар | | Аналитик чаралар | |
| рәвеш ясагыч кушымчалар (-***ча/-чә, -дай/-дәй***) | бәйлек һәм бәйлек сүзләр (***кебек, шикелле, сыман, төсле, итеп***) | мөнәсәбәтле сүзләр: ***шулай, шулай итеп, ничек – шулай, ничек – шулай итеп, ничек – шул рәвешле*** | теркәгечләр (***гүя, гүяки***) һәм теркәгеч сүзләр (***әйтерсең, диярсең***) |
| *(1)**Бала елагандай**, (2)урамда җил улый.* | *(1)**Бала елаган шикелле**, (2)урамда җил улый.* | *(1)**Бала ничек елый**, (2)урамда җил шулай улый.* | *(1)Урамда җил улый, (2)**бала елый диярсең**.* |

| |
|---|
| **Иярчен күләм җөмлә** баш җөмләнең күләм хәле урынында килә, яисә баш җөмләдәге мөнәсәбәтле сүз белән белдерелгән күләм хәлен ачыклый. Иярчен күләм җөмлә баш җөмләгә һәм **синтетик** (хәл фигыль формасы, *кадәр, хәтле, саен, дәрәҗәдә* бәйлек һәм бәйлек сүзләре), һәм **аналитик** (мөнәсәбәтле сүзләр) чаралар ярдәмендә иярә. |

| **ИЯРЧЕН КҮЛӘМ ҖӨМЛӘ** | |
|---|---|
| Синтетик чаралар | Аналитик чаралар |

| | | |
|---|---|---|
| хәл фигыль формалары (***-ганчы/-гәнче, -канчы/-кәнче***) | бәйлек һәм бәйлек сүзләр (***кадәр, хәтле, саен, дәрәҗәдә***) | мөнәсәбәтле сүзләр: ***шундый, шул кадәр, шул хәтле, ни кадәр – шул кадәр, ни хәтле – шул хәтле, күпме – шул хәтле*** |
| *(1)**Аяклары арганчы** (2)баласлар паркта йөгерделәр.* | *(1)**Кеше арткан саен** (2)эш арта.* (Мәкаль) | *(1)**Кеше никадәр күп булса**, (2)эш шул кадәр тиз эшләнә.* |

**Иярчен сәбәп җөмлә** баш җөмләнең сәбәп хәле урынында килә, яисә баш җөмләдәге мөнәсәбәтле сүз белән белдерелгән сәбәп хәлен ачыклый. Иярчен сәбәп җөмлә баш җөмләгә һәм **синтетик** (юнәлеш һәм төшем килеше кушымчалары, хәл фигыль формалары, *сәбәпле, күрә, аркасында, өчен* бәйлек һәм бәйлек сүзләре), һәм **аналитик** (мөнәсәбәтле сүзләр, *чөнки* теркәгече, көттерү интонациясе) чаралар ярдәмендә иярә.

| **ИЯРЧЕН СӘБӘП ҖӨМЛӘ** | | |
|---|---|---|
| Синтетик чаралар | | |
| юнәлеш (***-га/-гә, -ка/-кә***) һәм чыгыш (***-дан/-дән, -тан/-тән, -нан/-нән***) килеше кушымчалары | хәл фигыль формалары (***-гач/-гәч, -кач/-кәч, -магач/-мәгәч***) | бәйлек һәм бәйлек сүзләр (***күрә, аркасында, сәбәпле, өчен***) |
| *(1)**Эш күп булганга**, (2)мин кинога бармыйм.* | *(1)**Эш күп булгач**, (2)мин кинога бармыйм.* | *(1)**Эш күп булганга күрә**, (2)мин кинога бармыйм.* |

| **ИЯРЧЕН СӘБӘП ҖӨМЛӘ** |
|---|
| Аналитик чаралар |

| | | |
|---|---|---|
| мөнәсәбәтле сүзләр: ***шуңа, шуңа күрә, шуның аркасында, шул сәбәпле, шунлыктан*** | **чөнки** теркәгече | күтәрү интонациясе |
| [1]*Эш күп,* [2]***шуңа күрә мин кинога бармыйм.*** | [1]*Мин кинога бармыйм,* [2]***чөнки эш күп.*** | [1]***Мин кинога бармыйм:*** [2]*эш күп.* |

**Иярчен максат җөмлә** баш җөмләнең максат хәле урынында килә, яисә баш җөмләдәге мөнәсәбәтле сүз белән белдерелгән максат хәлен ачыклый. Иярчен максат җөмлә баш җөмләгә һәм **синтетик** (*өчен* бәйлеге һәм *дип* бәйлек сүзе), һәм **аналитик** (мөнәсәбәтле сүзләр) чаралар ярдәмендә иярә.

| **ИЯРЧЕН МАКСАТ ҖӨМЛӘ** | |
|---|---|
| Синтетик чаралар | Аналитик чаралар |
| ***өчен*** бәйлеге һәм ***дип*** бәйлек сүзе | мөнәсәбәтле сүзләр: ***шуның өчен, моның өчен*** |
| [1]***Бүлмәгә саф һава керсен дип,*** [2]*без тәрәзәләрне ачтык.* | [1]***Бүлмәгә саф һава керсен,*** [2]*шуның өчен без тәрәзәләрне ачтык.* |

**Иярчен шарт җөмлә** баш җөмләнең шарт хәле урынында килә, яисә баш җөмләдәге мөнәсәбәтле сүз белән белдерелгән шарт хәлен ачыклый. Иярчен шарт җөмлә баш җөмләгә һәм **синтетик** (шарт фигыль формасы, -*мы/-ме* сорау кисәкчәсе һәм *исә, икән* бәйлек сүзләре), һәм **аналитик** (мөнәсәбәтле сүзләр) чаралар ярдәмендә иярә. Синтетик чаралар янында еш кына ***әгәр*** теркәгече килә. Ләкин әлеге иярчен җөмлә синтетик төр итеп алына, чөнки *әгәр* теркәгечен төшереп тә калдырып була.

| **ИЯРЧЕН ШАРТ ҖӨМЛӘ** | | |
|---|---|---|
| Синтетик чаралар | | Аналитик чаралар |
| шарт фигыль (*-са/-сә*) формасы, *-мы/-ме* сорау кисәкчәсе | ***икән, исә*** бәйлек сүзләре | мөнәсәбәтле сүзләр: ***шулай булса, алайса, ул чагында, югыйсә*** |
| *(1)**Бүген кар яуса**, (2)иртәгә көн җылы булыр.* | *(1)**Бүген кар ява икән**, (2)иртәгә көн җылы булыр.* | *(1)**Бүген кар ява**, (2)алайса иртәгә көн җылы булыр.* |

**Иярчен кире җөмлә** баш җөмләнең кире хәле урынында килә, яисә баш җөмләдәге мөнәсәбәтле сүз белән белдерелгән кире хәлне ачыклый. Иярчен кире җөмлә баш җөмләгә һәм **синтетик** (шарт һәм хәл фигыль формаларына *да/дә* кисәкчәсе ялганып, 3 зат боерык фигыльнең юклык формасы, *карамастан* бәйлек сүзе), һәм **аналитик** (мөнәсәбәтле сүзләр) чаралар ярдәмендә иярә.

| **ИЯРЧЕН КИРЕ ҖӨМЛӘ** | | | |
|---|---|---|---|
| Синтетик чаралар | | | Аналитик чаралар |
| шарт фигыль ***-са/-сә + да/дә***; хәл фигыль ***-ып/-еп + да/дә*** | 3 зат боерык фигыльнең юклык формасы | ***карамастан*** бәйлек сүзе | мөнәсәбәтле сүзләр: ***шулай да, шуңа карамастан, шулай булса да*** |
| *(1)**Бүрене күпме генә ашатсаң да**, (2)ул барыбер урманга карый.* | *(1)**Бүрене күпме генә ашатма**, (2)ул барыбер урманга карый.* | *(1)**Бүрене ашатуга карамастан**, (2)ул барыбер урманга карый.* | *(1)**Бүрене күпме генә ашатма**, (2)шулай да ул урманга карый.* |

| **КАТЛАУЛЫ КУШМА ҖӨМЛӘ**<br>(өч һәм аннан да күбрәк компоненттан торган кушма җөмлә) | | |
|---|---|---|
| **күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә** | **күп иярченле катлаулы кушма җөмлә** | **катнаш кушма җөмлә** |
| кимендә өч компонент үзара бары тик тезүле бәйләнештә генә килә | бер баш җөмләгә кимендә ике иярчен җөмлә ияреп килә | компонентлар үзара тезүле дә, ияртүле юл белән дә бәйләнәләр |
| (1)Корал эшләр – (2)ир мактаныр, (3)кылыч кисәр – (4)кул мактаныр. (*Мәкаль*) | (1)Ир егетнең ике юлдашы бар: (2)берсе – батырлык, (3)икенчесе – тәвәккәллек. (*Мәкаль*) | (1)Иле бар (2)батыр хур булмас, (3)батыры бар (4)ил хур булмас. (*Мәкаль*) |

Өч һәм аннан да күбрәк компоненттан торган кушма җөмлә **катлаулы кушма җөмлә** дип атала. Аның өч төре билгеле: **күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә**, **күп иярченле катлаулы кушма җөмлә**, **катнаш кушма җөмлә**.

| **КҮП ИЯРЧЕНЛЕ КАТЛАУЛЫ КУШМА ҖӨМЛӘ** | | | |
|---|---|---|---|
| **тиңдәш ияртүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә** | **тиңдәш түгел ияртүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә** | **бер-бер артлы ияртүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә** | **берничә төр ияртүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә** |
| бер баш җөмләне кимендә ике иярчен җөмлә бер яктан гына | бер баш җөмләне кимендә ике иярчен җөмлә төрле яктан гына | бер баш җөмләгә кимендә ике иярчен җөмлә бер-бер артлы | бер баш җөмләгә кимендә өч иярчен җөмлә төрле юллар |

| ачыклап килә | ачыклап килә | ияреп килә | белән ияреп килә |
|---|---|---|---|
| (1)Ике нәрсә кешене картайтмый: (2)берсе – изге эш, (3)берсе – изге сүз. (*Мәкаль*) | (1)Ялкауга эш кушсаң, (2)атаң бирмәгән (3)үгетне бирер. (*Мәкаль*) | (1)Бәхете юкның (2)итәгенә бодай салсаң (3)түгелер. (*Мәкаль*) | |

| **Берничә төр иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә** | | |
|---|---|---|
| тиндәш иярү + тиндәш түгел иярү | тиндәш иярү + бер-бер артлы иярү | тиндәш түгел иярү + бер-бер артлы иярү |
| (1)Күпме еллар инде үтелсә дә, (2)Тормыш кырын синсез кичсәм дә, (3)Аерылганда биргән (4)кульяулыгың Йөрәк янымдагы кесәмдә. (*Наил Касыймов*) | (1)Һәр солдат белә: (2)җиңү килсә дә, (3)шушы җиңү хакына кайсыдыр ятып калыр, (4)кайсыдыр мондый матур таңнарны һичкайчан күрмәс. (*Гомәр Бәширов*) | (1)Мин булганга (2)син куанган кебек, (3)мин куанам хәзер (4)син булганга. (*Шәмсия Җиһангирова*) |

| КАТНАШ КУШМА ҖӨМЛӘ | | |
|---|---|---|
| (1)Агачы нинди, (2)алмасы шундый; (3)анасы нинди, (4)баласы шундый. (*Мәкаль*) | (1)Таң пәрдәсен ачып, кояш чыккан чакта, (2)Йөрәгеңә бәхет үрелер, (3)Шатлыкларың җем-җем энҗе чыклар | (1)Йөрәк теләсә кемгә ачылмый, (2)йөрәккә ачкыч яратып булмый, (3)йөрәккә ярату ачкычы кирәк: (4)йөрәкне яратып кына ачып була. |

| | | |
|---|---|---|
| | булып,<br>Юлларыңа синең <u>сибелер</u>. (*Шәмсия Җиһангирова*) | (*Марсель Галиев*) |

| |
|---|
| Катнаш кушма җөмләдә ике иярчен җөмлә аерым-аерым ике баш җөмләгә иярсә, алар арасына тиңдәшлек яисә тиңдәш түгеллек билгесе куелмый. Бер иярчен җөмлә берничә баш җөмләгә ияреп килә ала. Иярчен җөмлә тезүле бәйләнештә килгән берничә җөмләнең берсенә генә иярсә, баш җөмлә дип бары тик шул компонент кына алына, ә калган шакмаклар буш кала. |

| **ТЕКСТ** | |
|---|---|
| **макротекст**<br>(зур күләмле әсәр) | **микротекст**<br>(кечерәк күләмле әсәр) |
| повесть, пьеса, мәкалә | әсәрнең бер бүлеге, абзац, хикәя |

| **ТЕКСТ** | | |
|---|---|---|
| **хикәяләү**<br>(повествование) | **тасвирлау**<br>(описание) | **фикерләү**<br>(рассуждение) |
| Вакыйгалар, аларда катнашучыларының эш-гамәлләре турында хронологик тәртиптә сөйләү яки язу. | Тирә-юньнең, кешеләрнең, әйберләрнең, күренешләрнең үзенчәлекләре турында язу; аларны сурәтләп бирү. | Өч өлешкә бүленә: аңлатма, исбат итү, нәтиҗә. Еш кына *беренчедән*, *икенчедән*, *гомумән*, *чөнки* кебек сүзләр кулланыла. |

| | | |
|---|---|---|
| матур әдәбият әсәрләре | пейзажны, кеше портретларын сурәтләгән текстлар. | фәнни китаплар, дәреслектәге текстлар |

Без фикеребезне укучыга яисә тыңлаучыга ике төрле юл белән хәбәр итә алабыз: сөйләп яисә язып. Димәк, сөйләм ике төрле: **телдән сөйләү** һәм **язма рәвештә** була икән.

Сөйләмне башкаручы сөйләүче, ягъни автор була.

Сөйләүче сөйләгәндә кеше сүзләрен дә катнаштырырга мөмкин. Бу очракта сөйләм ике өлештән: сөйләүченең үз сүзләреннән һәм башка кеше сүзләреннән тора.

Текстта сөйләүченең үз сүзләре – **автор сөйләме**, сөйләүче кулланган башка кеше сүзләре **чит сөйләм** дип атала.

| **ЧИТ СӨЙЛӘМ** | |
|---|---|
| **туры сөйләм** | **кыек сөйләм** |
| ***Әни, песнәк нигә тәрәзәне чукый?*** *– дип сорады Әнисә.* | *Әнисә әнисеннән* ***песнәкләрнең ни өчен тәрәзәне чукыганнары хакында*** *сорады.* |
| Чит сөйләм **үзгәртелмичә** кулланыла. | Чит сөйләм **үзгәртелеп** кулланыла. |

| **ТУРЫ СӨЙЛӘМ ТӨРЛӘРЕ** | | |
|---|---|---|
| **диалог** | **монолог** | **цитата** |
| - *Сеңелем, син кайчан кайтасың?*<br>- *Дәресләр сәгать икедә тәмамлана, шуннан соң кайтам.* | *Гөлфия тугызынчы сыйныфта укый. Мәктәптән кайткач, бию түгәрәгенә бара. Ул бик матур бии.* | *Ш.Галиев: “Төннәр яктырды, күңелләр яктырды: кар яуды!” – дип язган.* |

| | | |
|---|---|---|
| - *Ярар, мин сине өйдә көтәрмен.*<br>- *Очрашканга кадәр.* | *Концертларда ул бик теләп катнаша.* | |
| Ике яки берничә кешенең үзара сөйләшү. | Бер генә кешенең тыңлаучы яисә укучы өчен сөйләме. | Язма әсәрдән алынган туры сөйләм. |

| ТУРЫ СӨЙЛӘМ ЯНЫНДА ТЫНЫШ БИЛГЕЛӘРЕ | | | |
|---|---|---|---|
| А: «Т?»<br>А: «Т».<br>А: «Т!» | «Т? » – а.<br>«Т», – а.<br>«Т! » – а. | А: «Т?» – а.<br>А: «Т», – а.<br>А: «Т!» – а. | «Т, – а. – Т».<br>«Т? – а. – Т».<br>«Т, – а, – т». |
| *Әбиемнең тавышы ишетелде: «Кем бар анда?»* | *«Кем бар анда?» – дип сорады әбием.* | *Әбием: «Кем бар анда?» – дип сорады.* | *«Кем бар анда? – дип сорады әбием. – Улым кайткан икән».* |

## ПУНКТУАЦИЯ

| **НОКТА**<br>түбәндәге очракларда куела: | | |
|---|---|---|
| хикәя җөмләдән һәм тыныч тавыш белән әйтелгән боерык җөмләдән соң | баштагы бер яки берничә хәрефе белән кыскартылып язылган сүзләрдән соң | драма әсәрләрендәге персонаж исемнәреннән соң |

| **?** | **!** | **?!** |
|---|---|---|
| сорау җөмләдән соң куела | көчле тойгы (көчле боеру, үтенү, ялыну, шатлык, соклану, гаҗәпләнү, үкенү, ирония һәм ачулану) белән әйтелгән җөмләдән соң куела | көчле тойгы белән әйтелгән сорау җөмләдән соң куела |

| КҮП НОКТАЛАР | |
|---|---|
| цитаталарда төшереп калдырылган сүзләр яки җөмләләр урынына куела | төрле сәбәпләр аркасында сөйләмнең әйтелеп бетмәвен күрсәтү өчен куела |

| **КУШТЫРНАКЛАР**<br>түбәндәге очракларда куела: | | |
|---|---|---|
| диалог формасында язылмаган туры сөйләмне аеру өчен | китап, газета, журнал һәм төрле оешма, предприятие исемнәрен аеру өчен | гадәти мәгънәсеннән башкарак мәгънә белдергән сүзләрне аеру өчен |

Предприятие яки оешма исемнәреннән соң *исемендәге* сүзе килсә, куштырнаклар куелмый.

| **ӨТЕР**<br>түбәндәге очракларда куела: | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| тиңдәш кисәкләр арасына | аерымланган кисәкләрне аеру өчен | кереш сүзләрне, артык җәенке булмаган кереш җөмләләрне, тынычрак тавыш белән әйтелә торган эндәш сүзләрне, ымлыкларны һәм *әйе, юк* сүзләрен аеру өчен | тезмә кушма җөмләдәге гади җәмләләр арасына | иярченле кушма җөмләдәге җөмләләр арасына | мәгънәне көчәйтү өчен кабатланып килгән сүзләр арасына |

| **НОКТАЛЫ ӨТЕР**<br>түбәндәге очракларда куела: | |
|---|---|
| үз эчендә өтерләр булган җәенке тиңдәш кисәкләр арасына | тезмә кушма җөмләдәге гади җөмләләрнең үз эчләрендә өтерләр булса яки алар үзара артык тыгыз мәгънә мөнәсәбәтендә тормасалар, алар арасына |

| **ИКЕ НОКТА**<br>түбәндәге очракларда куела: | | | |
|---|---|---|---|
| санап кителә торган тиңдәш кисәкләр | фигыль белән бирелгән хәбәргә | баш җөмлә белән иярчен җөмлә | автор сүзләреннән соң (туры сөйләм |

| | | | |
|---|---|---|---|
| алдыннан көттерү паузасы ясалган урында | ияргән аныклагычлар алдында *ягъни, башкача әйткәндә, шул исәптән, шул җөмләдән* кебек ярдәмче сүзләр килмәсә, шул урынга | арасында көттерү паузасы ясалган урынга | алдыннан) көттерү паузасы ясала, шул урынга |

| **СЫЗЫК**<br>түбәндәге очракларда куела: |
|---|
| Җөмләдәге исемнәр яки исем урынында йөри торган сүзләр үзләре генә (ярдәмче фигыльләрдән һәм *-мын, -мен, -сың, -сең,-сыз, -сез, -быз, -без* кебек кушымчалардан башка) хәбәр булып килгәндә, ия белән хәбәр арасына |
| Ияне аергыч дип тану куркынычы булганда, иядән соң |
| Кискен каршы куюны белдергән теркәгечсез тиңдәш кисәкләр һәм җөмләләр арасына |
| Тиңдәш кисәкләрдән соң килгән гомумиләштерүче сүзләр алдыннан |
| Аныкланмышы исем белән бирелгән аныклагыч алдыннан |
| Аныклагыч тиңдәш яки бик җәенке булып, аның чиген билгеләү укучыда кыенлык тудырырлык булса, аныклагыч ике яктан да сызык белән аерыла |
| Текстның укылышына зыян китерердәй кереш җөмләләрне аеру өчен |
| Хәбәре әйтелмәгән я ким җөмләнең пауза ясала торган урынында |
| Ике чикне күрсәтә торган сүзләр арасына |
| Туры сөйләм диалог формасында язылганда, һәрбер реплика алдыннан |
| Туры сөйләм уртасында һәм аннан соң килгән автор сүзләре янында сызык башка билгеләр белән бергә куела. |
| Җөмләләр арасында кискен каршы куюны белдергән *барыбер* сүзе алдыннан сызык өтер белән бергә куела. |

| **ҖӘЯЛӘР**<br>түбәндәге очракларда куела: | | | |
|---|---|---|---|
| сөйләм барышында өстәмә аңлатма бирә торган кереш сүз һәм кереш җөмләләрне аеру өчен | аныкланмышның тәрҗемәсе яки башка исеме булган аныклагыч җәяләр эченә алына | өземтәнең авторы яки чыганагы күрсәтелгәндә | драма әсәрләрендә диалоглар эченә кертелгән автор ремаркаларын (аңлатмаларын) аеру өчен |

## БЕЛЕМЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ

**Бер дөрес җавапны билгеләгез:**

**1.** Синтаксис нәрсәне өйрәнә?

А) сүзләр байлыгын;

Б) сүзләр ясалышын;

В) сүзләр һәм җөмләләр бәйләнешен;
Г) сүзләрне төркемләү мәсьәләсен.

**2.** *Бүгенгедәй хәтердә* сүзтезмәсендә бәйләүче чара нинди?
А) сүз тәртибе;
Б) -*дәй* кушымчасы;
В) урын-вакыт килеше кушымчасы;
Г) янәшә тору.

**3.** *Ике атнадан кайту* сүзтезмәсенең төзелешен билгеләгез:
А) гади сүзтезмә;
Б) катлаулы сүзтезмә;
В) тезмә сүзтезмә;
Г) фразеологик сүзтезмә.

**4.** Аергычка хас үзенчәлекне сайлап алыгыз:
А) исем белән бирелгән кисәкне ачыклап килә;
Б) ия турында нәрсә дә булса хәбәр итә;
В) эш-хәрәкәтнең үтәлүенә бәйле затны, предметны белдерә;
Г) эш-хәрәкәтнең үтәлү характерын белдерә.

**5.** Аерып бирелгән сүзләр нинди җөмлә кисәге булып килә: *Киткән урманга **утынга**, ялгызы бер ат җигеп (Г.Тукай).*
А) туры тәмамлык;
Б) кыек тәмамлык;
В) максат хәле;
Г) сәбәп хәле.

**6.** Аерып бирелгән сүзләр нинди җөмлә кисәге булып килә: ***Сокланып туймаслык** җиһан иде биредә (В.Имамов).*
А) кыек тәмамлык;
Б) аергыч;
В) рәвеш хәле;
Г) күләм хәле.

**7.** Аерып бирелгән төзелмәнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез:
*Салкынга **түзәр әмәле калмагач**, карчык, төн уртасында торып, мичкә ут тергезде дә мич авызына аркасын куеп утырды* (Л.Зөлкарнәй).
А) хәбәр
Б) вакыт хәле
В) сәбәп хәле
Г) рәвеш хәле

**8.** Бу өзектә аерып бирелгән төзелмәнең төрен билгеләгез: *Моңа кадәр күренмәгән кошлар, таң калдырып, җыр башлап җибәрәләр. Волга ягыннан җиләс җил исеп китә.* ***Апрель җиле, язгы җил****... (И.Абдуллин).*

А) ким җөмлә;

Б) өстәлмә;

В) күзаллаулы баш килеш;

Г) атау җөмлә.

**9.** Бер составлы фигыль җөмләнең төрен билгеләгез: *Сүзне алардан башларга кирәк булгандыр миңа (Р.Төхвәтуллин).*

А) билгеле үтәүчеле җөмлә;

Б) билгесез үтәүчеле җөмлә;

В) гомум үтәүчеле җөмлә;

Г) үтәүчесез җөмлә.

**10.** Тыныш билгеләренең дөрес куелган вариантын билгеләгез:

*Читтә тапкан бәхет бер атналык тәхет кенә ул бүген бар иртәгә юк* (Р.Вәлиев).

А) *Читтә тапкан бәхет – бер атналык тәхет кенә ул: бүген бар, иртәгә юк.*

Б) *Читтә тапкан бәхет бер атналык тәхет кенә ул, бүген бар, иртәгә юк.*

В) *Читтә тапкан бәхет бер атналык тәхет кенә ул, бүген бар – иртәгә юк.*

Г) *Читтә тапкан бәхет – бер атналык тәхет кенә ул, бүген бар, иртәгә юк.*

**11.** Җөмләдә бәйләүче чараны билгеләгез: *Әмма, иркәм, син шуны онытма: тургайлар күккә никадәр генә биек менеп сайрасалар да, оя корырга барыбер җиргә кайталар (Г.Рәхим).*

А) 2 зат боерык фигыльнең берлек формасы;

Б) санау интонациясе;

В) *шуны* мөнәсәбәтле сүзе;

Г) *әмма* теркәгече.

**12.** Җөмләдә бәйләүче чараны билгеләгез: *Яныңа килгәннәрне куарга ашыкма, юкса килүче дә булмас (Т.Миңнуллин).*

А) 2 зат боерык фигыльнең берлек формасы;

Б) *юкса* ияртүче теркәгеч;

В) санау интонациясе;

Г) күтәрү интонациясе.

**13.** Җөмләнең структур төрен билгеләгез:

*Ярату өчен матур йөрәк кирәк, бәхетле булу өчен батыр йөрәк кирәк* (Г.Гыйльманов).

А) теркәгечле тезмә кушма җөмлә

Б) теркәгечсез тезмә кушма җөмлә

В) синтетик иярченле кушма җөмлә

Г) аналитик иярченле кушма җөмлә

**14.** Иярчен җөмләнең функциональ-семантик төрен билгеләгез:
*Син белеп тор: икебезнең*
*Мәхәббәттән башка*
*Әйләнермен мин тимергә*
*Йә булмаса ташка* (Р.Миңнуллин).

А) иярчен шарт җөмлә
Б) иярчен тәмамлык җөмлә
В) иярчен хәбәр җөмлә
Г) иярчен кире җөмлә

**15.** Иярчен җөмләнең функциональ-семантик төрен билгеләгез:
*Мәхәббәт сагышы булып*
*Соңгы карлар яуса да,*
*Язгы җыр булып исемең*
*Күңелемдә саклана* (Ш.Җиһангирова).

А) иярчен шарт җөмлә
Б) иярчен рәвеш җөмлә
В) иярчен тәмамлык җөмлә
Г) иярчен кире җөмлә

**16.** Катлаулы кушма җөмләнең төрен билгеләгез: *Чүлмәк чуенга бәрелсә дә, чуен чүлмәккә бәрелсә дә, чүлмәк ватыла (Мәкаль).*

А) катнаш кушма җөмлә;
Б) тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;
В) тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;
Г) күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә.

**17.** Катлаулы кушма җөмләнең төрен билгеләгез: *Ул – кайгылы, ул – ачулы, ул ярсулы иде (Н.Фәттах).*

А) бер-бер артлы иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;
Б) тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;
В) күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә;
Г) тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә.

**18.** Җөмләдә компонентларның санын билгеләгез:
*Җирдә кеше торса торсын,*
*Эзе калсын тирән булып,*
*Үзе үлсә, эше калсын*
*Мең яшәрлек имән булып (М.Җәлил).*

А) 2;
Б) 3;
В) 4;

Г) 5.

**19.** Җөмләдә компонентларның санын билгеләгез: *Кулыңдагы кемнәрдер бүләк иткән затлы чәчәкләр янына кыр ромашкасы белән бакчалардагы сирень чәчәкләре бүләк итсәм – ачуланма! (Г.Гыйльман).*

А) 2;
Б) 3;
В) 4;
Г) 5.

**20.** Тыныш билгесенең дөрес куелган вариантын табыгыз:

*Күк аяз көннәр коры тора тик шунысы аяныч алтын вакыт заяга үтә* (М.Рафиков).

А) *Күк аяз: көннәр коры тора, тик шунысы аяныч, алтын вакыт заяга үтә!*
Б) *Күк аяз, көннәр коры тора, тик шунысы аяныч – алтын вакыт заяга үтә!*
В) *Күк аяз, көннәр коры тора, тик, шунысы аяныч: алтын вакыт заяга үтә!*
Г) *Күк аяз, көннәр коры тора, тик шунысы аяныч: алтын вакыт заяга үтә!*

**1 нче бирем. Җөмләләргә тиешле тыныш билгеләрен куеп чыгыгыз.**

1. Без өйгә кайтып кергәндә кояш баеп бара иде инде. (М.Гафури)
2. Төн буе буран котырганга юл бик начар иде. (И.Гази)
3. Ул үзенең егетләре белән урманга килеп җиткәндә урман авызында аны шул ук Гыйльметдин каршы алды. (И.Гази)
4. Ае юк төннең йолдызлары болытларга күмелгән. (Һ.Такташ)
5. Аптырап Хәлимә ягына борылсам кыздан җилләр искән. (Ф.Шәфигуллин)
6. Кайчагында аның күңеле күз яшьләре чыгарлык дәрәҗәдә аеруча бер җилкенү белән дулкынлана башлый. (Г.Бәширов)
7. Урман каравылчысы түбәдән кар ишелгән шикелле тавыш белән дөбердәтеп көлде. (М.Галиев)
8. Зөһрә ханым минем белән бергә китергә риза булгач күңелемне аеруча бер рух күтәренкелеге биләп алган иде. (Ә.Еники)
9. Дөнья киңлегеннән ни файда аяк киемең тар булса? (Мәкаль)
10. Үзеңне әдәбият чаклы әдәбияттан халык рухының көзгесе булган әдәбияттан өстен куярга азаплану берәүне дә бизәми минемчә. (Г.Ахунов)

**2 нче бирем. Тиешле тыныш билгеләрен куеп, баш кисәкләрнең асларына сызыгыз, җөмлә чикләрен билгеләгез.**

1. Хөрмәт итәм дусларымны
   Гел үзгәреп торсалар да. (М.Әгъләмов)

2. Аяк тавышы ишетелгән саен тәрәзә пәрдәсен күтәреп урамны күзәтте. (А.Гыйләҗев)

3. Күңелең сөймәгән кешедән ярдәм сорама. (Мәкаль)

4. Чартлап торган таш өстенә су килеп төшү белән мунча ишеге шартлап ачылып китте. (Батулла)

5. Мин агачлар ышыгында утырган таныш өй янына килеп җиткәндә яңгыр туктаган иде инде. (М.Галиев)

6. Танышы күрми калмасын дип аягүрә басты күңеллеләнеп ияген сыйпап куйды. (Г.Бәширов)

7. Бүре толыбы бар кеше юлдашының туңганын белмәс. (Мәкаль)

8. Беренче кыңгырау чылтыраса да класска керергә уйлап та караган кеше юк. (М.Мәһдиев)

**3 нче бирем. Баш җөмләдән өтер белән аерылган синтетик иярчен җөмләләрнең урыннарын өтер куелмый торган итеп үзгәртеп языгыз.**

1. Кояш түбәнәйгән саен, эскертләр биегәя бара. (Ф.Яруллин)
2. Ул кереп киткәч тә, звонок булды. (М.Мәһдиев)
3. Сугыш башлану белән, Низамны фронтка алып киткәннәр. (Х.Сарьян)
4. Аягы аксак булу сәбәпле, сугышка китми калган. (Г.Ахунов)
5. Чүлләрдә сусаган кеше чишмәгә ташлангандай, Фәнияр китапка ташланды. (Ф.Яруллин)
6. Дуслар ишәйсә, дошман калтырый. (Мәкаль)

**4 нче бирем. Икешәрләп бирелгән җөмләләрдән синтетик иярчен җөмләле кушма җөмләләр төзегез. Бер очракта синтетик җөмлә баш җөмләдән өтер белән аерылсын, икенче очракта өтер белән аерылмый торган булсын.**

*Үрнәк: Яз җитте. Карлар эреде. – 1) Яз җиткәч, карлар эреде. 2) Карлар яз җиткәч эреде.*

1. Укытучы бишле куйды. Алсу шатланды.
2. Әни кайтсын. Балалар җиләк җыярга барырлар иде.
3. Урамда машина тавышы ишетелде. Картлар тиз генә чыгып бастылар.
4. Укучылар укыганнар. Китапларны укытучы китапханәгә тапшырды.

## Аңлатмалы сүзлек

**Аергыч** – җөмләнең предмет төшенчәсен атый торган кисәгенә ияреп, шул предметларның билгесен, санын һәм кемгә (нәрсәгә) каравын белдерә торган иярчен кисәк.

**Аергыч тезем** – санау бүлеге аергычлардан яки аергыч җөмләләрдән тора торган тезем.

**Аерылмыш** – аергыч буйсынган сүз.

**Аерымланган кисәкләр** – язуда тыныш билгеләре белән аерыла торган кисәкләр.

**Актуаль киәкләр** – сөйләм предметын һәм сөйләм яңалыгын белдерә торган сүзләр.

**Аналитик кушма җөмлә** – иярчен җөмләсе баш җөмләгә аналитик чара ярдәмендә бәйләнгән һәм формасы белән гади җөмләгә охшаган иярченле кушма җөмлә.

**Ачыклагыч** – ияртүче кисәктән соң килеп, аңа аныклык кертә торган иярчен кисәк.

**Ачыклагыч тезем** – санау бүлеге аныклагычлардан яки аныклагыч җөмләләрдән тора торган тезем.

**Аныклаулы мөнәсәбәт** – иярүче сүзнең ияртүче сүзгә өстәмә аныклык бирүе.

**Баш җөмлә** – иярченле кушма җөмләдә иярчен җөмләне ияртеп килгән җөмлә.

**Башкарылу** – ияртүче сүзнең иярүче сүзнең нинди дә булса бер килеш формасын алуын яки кайсы да булса бер бәйлек белән килүен таләп итүе.

**Бер составлы җөмлә** – җөмләнең барлык кисәкләре дә бер генә баш кисәк янына оешып беткән җөмлә.

**Бер составлы исем җөмлә** – баш кисәге исем яки исемләшкән башка сүзләр белән бирелгән һәм әйберләрнең, билгеләрнең яки төрле күренешләрнең исемнәрен атау юлы белән аларның булу-булмауларын хәбәр итә торган җөмлә.

**Бер составлы фигыль җөмлә** – баш кисәге фигыль һәм процесс белдерә торган башка сүзләр белән бирелгән җөмлә.

**Бер-бер артлы иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә** – иярчен җөмләләре баш җөмләгә бер-бер артлы ияреп килгән кушма җөмлә.

**Берничә төр иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә** – берничә төр бәйләнеш бергә кулланылган кушма җөмлә.

**Билгеле үтәүчеле җөмлә** – баш кисәктән аңлашылган процессның үтәүчесе конкрет билгеле булган бер составлы җөмлә.

**Билгесез үтәүчеле җөмлә** – баш кисәктән аңлашылган процессның үтәүчесе конкрет билгеле бумаган җөмлә.

**Боеру җөмлә** – сөйләүченең боеруын, үтенүен, чакыруын, киңәшен белдерә торган җөмлә.

**Вакыт тезем** – санау бүлеге вакыт хәлләреннән яки вакыт җөмләләрдән тора торган тезем.

**Вакыт хәле** – процессның үтәлү вакытын яки билгенең булу-булмау вакытын белдерә торган иярчен кисәк.

**Гади җөмлә** – бер генә хәбәрлектән торган җөмлә.

**Гади кушма җөмлә** – ике җөмләдән торган кушма җөмлә.

**Гади сүзтезмә** – ике генә мөстәкыйль сүздән торган сүзтезмә.

**Гади хәбәр** – бер генә сүз белән белдерелгән хәбәр.

**Гомумиләштерүче сүз** – тиңдәш кисәкләрнең барысын бергә җыеп, гомумиләштереп әйтә торган кисәк.

**Грамматик бөтенлек** – тексттагы мөстәкыйль җөмләләрнең, абзацларның грамматик чаралар белән бәйләнүе.

**Диалог** – ике яки берничә кешенең үзара сөйләшүе формасында бирелгән туры сөйләм.

**Җәенке җөмлә** – иярчен яисә модаль кисәкләр файдаланылган җөмлә.

**Җөмлә** – сөйләмнең фикерне, кичерешне һәм ихтыярны хәбәр итә һәм сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдерә торган иң кыска берәмлеге.

**Җөмләнең модаль кисәкләре** – сөйләүченең чынбарлыкка, тыңлаучыга, җөмлә эчтәлегенә, төзелешенә мөнәсәбәтен белдерә торган кисәк.

**Җөмләнең модальлек белдерүе** – сөйләүченең чынбарлыкка, тыңлаучыга, сөйләмгә мөнәсәбәт белдерүе.

**Җөмләнең парадигмасы** – билгеле бер гомуми мәгънә тирәсенә тупланган синтаксик формалар системасы.

**Җөмләнең хәбәрлек белдерүе** – фикерне, кичерешне һәм ихтыярны хәбәр итүе, ягъни аларны чынбарлыктан алып чынбарлыкка төбәп әйтүе.

**Җыйнак җөмлә** – баш кисәкләрдән генә торган, иярчен кисәкләре, модаль кисәкләр булмаган җөмлә.

**Инкяр җөмлә** – нәрсәне булса да инкяр итә торган җөмлә.

**Интонация** – сөйләгәндә тавышның төрлечә хәрәкәте.

**Ирекле сүзтезмә** – кирәк булганда гына, ягъни сөйләм барышында гына ясалган һәм кисәкләре арасында реаль мәгънә мөнәсәбәте югалмаган сүзтезмә.

**Исем хәбәр** – фигыльдән кала башка сүз төркемнәре белән белдерелгән хәбәр.

**Ия** – җөмләдә баш килештәге сүз белән бирелеп, хәбәрне үзенә ияртә торган грамматик бәйсез кисәк.

**Ия тезем** – санау бүлеге ияләрдән яки ия җөмләләрдән тора торган тезем.

**Ияртүле бәйләнеш** – сүзләрнең бер-берсенә буйсынып килүе.

**Иярчен аергыч җөмлә** баш җөмләнең аергычы урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән аергычның конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

**Иярчен аныклагыч җөмлә** баш җөмләдән аңлашылган төшенчәне, фикерне өстәмә аныклап килә.

**Иярчен вакыт җөмлә** баш җөмләнең вакыт хәле урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән вакыт хәленең конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

**Иярчен җөмлә** – иярченле кушма җөмләдә баш җөмләгә ияреп, буйсынып килгән җөмлә.

**Иярчен ия җөмлә** баш җөмләнең иясе урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән иянең конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

**Иярчен кереш җөмлә** җөмләнең, яисә аның кисәгенең эчтәлеген кайсы яктандыр өстәмә рәвештә аныклап, комментарий биреп килә.

**Иярчен кире җөмлә** баш җөмләнең кире хәле урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән кире хәленең конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

**Иярчен күләм җөмлә** баш җөмләнең күләм хәле урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән күләм хәленең конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

**Иярчен максат җөмлә** баш җөмләнең максат хәле урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән максат хәленең конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

**Иярчен рәвеш җөмлә** баш җөмләнең рәвеш хәле урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән рәвеш хәленең конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

**Иярчен сәбәп җөмлә** баш җөмләнең сәбәп хәле урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән сәбәп хәленең конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

**Иярчен тәмамлык җөмлә** баш җөмләнең тәмамлыгы урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән тәмамлыкның конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

**Иярчен урын җөмлә** баш җөмләнең урын хәле урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән урын хәленең конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

**Иярчен хәбәр җөмлә** баш җөмләнең хәбәре урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән хәбәрнең конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

**Иярчен шарт җөмлә** баш җөмләнең шарт хәле урынында килә яисә баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән шарт хәленең конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

**Иярчен кисәк** – төгәлләүле һәм аныклаулы мөнәсәбәткә кергән сүзләрнең иярүчесе.

**Иярченле кушма җөмлә** – аерым җөмләләре ияртү юлы белән бәйләнгән җөмлә.

**Катлаулы кушма җөмлә** – икедән артык җөмләдән торган кушма җөмлә.

**Катлаулы сүзтезмә** – икедән артык мөстәкыйль сүздзән торып, гади сүзтезмәләргә таркалмый торган сүзтезмә.

**Катнаш кушма җөмлә** – аерым җөмләләрнең бер төрләре үзара ияртүле юл белән бәйләнеп, икенче төрләре тезүле юл белән бәйләнгән катлаулы кушма җөмлә.

**Кереш сүз** – сөйләүченең сөйләм эчтәлегенә, төзелешенә һәм сөйләм обстановкасына мөнәсәбәтен белдерә торган сүз.

**Ким җөмлә** – контекст, обстановка, мимика һәм жестлардан аңлашыла торган кисәге яки сүз формасы кулланылмаган җөмлә.

**Кире тезем** – санау бүлеге кире хәлләр яки кире җөмләләр белән бирелгән тезем.

**Кире хәл** – ияртүче кисәктәе аңлашылган процессның киресе булачагын белдерә торган иярчен кисәк.

**Кушма җөмлә** – берничә хәбәрлектән торган җөмлә.

**Кушма җөмләнең компонентлары** – кушма җөмлә составындагы гади җөмләләр.

**Кушма хәбәр** – грамматик мәгънәләре ярдәмлек сүзләр белән бирелгән хәбәр.

**Күләм хәле** – процессның яки билгенең күләмен, дәрәҗәсен белдерә торган иярчен кисәк.

**Күп иярченле кушма җөмлә** – икедән артык җөмлә үзара ияртү юлы белән бәйләнгән кушма җөмлә.

**Күп тезмәле кушма җөмлә** – икедән артык җөмлә үзара бары тезү юлы белән генә бәйләнгән кушма җөмлә.

**Күтәрелмә тезем** – иң элек төп бүлек, аннан соң күтәрелә бара торган интонация белән санау бүлеге әйтелә торган тезем.

**Күтәрелүче интонация** – әкренләп күтәрелә бара һәм үзенең иң югары ноктасында кинәт туктап кала торган интонация.

**Кыек сөйләм** – үзгәртелеп кулланылган чит сөйләм.

**Кыек тәмамлык** – процесс турыдан-туры кагылмый торган әйберне, затны белдергән тәмамлык.

**Логик басым** – җөмләдә мәгънәсе буенча иң әһәмиятле сүзгә төшә торган басым.

**Макротекст** – өйрәнү өчен алынган зур текст.

**Максат тезем** – санау бүлеге максат хәлләреннән яки максат җөмләләрдән тора торган тезем.

**Максат хәле** – процессның үтәлү-үтәлмәү, билгенең булу-булмау максатын белдерә торган иярчен кисәк.

**Микротекст** – өйрәнү өчен алынган күләме ягыннан кечкенә текст.

**Модальлек** – сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәте.

**Монолог** – персонажның үз-үзенә, башка берәүгә яисә халыкка мөрәҗәгать ителгән сөйләме.

**Номинативлык** – сүзләрнең һәм сүзтезмәләрнең атау функциясе.

**Өлешчә инкарь җөмлә** – хәбәрдән башка нинди дә булса бер кисәге белдергән төшенчә инкарь ителгән җөмлә.

**Өстәлмә** – мәгънәсенә ныграк игътибар иттерү өчен, төп җөмлә ахырына чыгарылган һәм аерым җөмлә интонациясе белән әйтелгән сүз яки сүзтезмә.

**Прагматик мөнәсәбәт** – сөйләм семантикасының тыңлаучыга мөнәсәбәте.

**Предикат** – алынган төшенчә турында әйтелгән яңалык.

**Пропозиция** – берәр эш-хәл турында хәбәр итү.

**Пунктуация** – тыныш билгеләрен кую турындагы кагыйдәләр җыелмасы.

**Раслау җөмлә** – нәрсәне дә булса раслый торган җөмлә.

**Рәвеш тезем** – санау бүлеге рәвеш хәлләреннән яки рәвеш җөмләләрдән тора торган тезем.

**Рәвеш хәле** – процессның ничек һәм ни рәвешле үтәлүен яисә нинди дә булса бер хәлнең яки билгенең билгесен, сыйфатын белдерә торган иярчен кисәк.

**Редупликация күренеше** – сүзләрне кабатлап куллану.

**Реплика** – диалог эчендә аерым кеше сүзләре.

**Референция** – сөйләм семантикасының чынбарлыкка мөнәсәбәте.

**Риторик сорау җөмлә** – җавап таләп итми торган, бары тик формасы ягыннан гына сорау җөмләләргә кертелә торган сорау җөмлә.

**Сәбәп тезем** – санау бүлеге сәбәп хәлләреннән яки сәбәп җөмләләрдән тора торган тезем.

**Сәбәп хәле** – процессның үтәлү-үтәлмәү яки билгенең булу-булмау сәбәбен белдерә торган иярчен кисәк.

**Семиотика** – нинди дә булса бер хәбәргә ия булган билгенең төзелешен һәм кулланылышын гомумән алып өйрәнә торган методологик фән.

**Синтагма** – сөйләмнең бер-берсеннән паузалар һәм башка ритмомелодик чаралар белән аерыла торган мәгънәле кисәк.

**Синтаксик фразеологизмнар** – сүзләр бәйләнешенең хәзерге нормаларына сыймый торган сүзтезмәләр һәм җөмләләр.

**Синтаксис** – телнең сөйләм төзелешен өйрәнә торган фән.

**Синтетик кушма җөмлә** – иярчен җөмләсе баш җөмләгә синтетик чара ярдәмендә бәйләнгән һәм формасы белән гади җөмләгә охшамаган иярченле кушма җөмлә.

**Сорау җөмлә** – нинди дә булса сорауны белдерә торган җөмлә.

**Сөйләм** – телнең хәрәркәттәге чагы, аралашу ысулы.

**Сөйләм адресаты** – тыңлаучы.

**Сөйләм субъекты** – сөйләүче.

**Сөйләмнең модальлеге** – сөйләмнең чынбарлыкка сөйләүче мөнәсәбәтен белдерергә сәләтле булуы.

**Сөйләмнең хәбәрлеге** – сөйләмнең яңалык хәбәр итәргә сәләтле булуы.

**Субъект** – аның турында нининдер яңалык әйтү өчен алынган төшенчә.

**Сүз җөмлә** – җөмләнең традицион кисәкләренә туры килеп бетми һәм башка кисәкләрне ияртеп җәенкеләнә алмый торган сүзләрдән оешкан җөмлә.

**Сүзтезмә** – ике яки берничә мөстәкыйль сүзнең төгәлләүле мөнәсәбәткә керүе нәтиҗәсендә ясалган һәм төгәлрәк төшенчәне белдерә торган төзелмә.

**Тәмамлык** – җөмләнең процесс белдерә торган сүз белән бирелгән теләсә кайсы кисәгенә ияреп, процессның (яки билгенең) объектын, үтәүчене яки нинди дә булса бер хәл кичерә торган әйберне (затны) һ.б. мәгънәләрне белдерә торган иярчен кисәк.

**Тәмамлык тезем** – санау бүлеге тәмамлыклардан яки тәмамлык җөмләләрдән тора торган тезем.

**Тезем** – тиңдәш кисәкләре яки тиңдәш җөмләләре күп булу аркасында бик нык җәенкеләнгән гади яки кушма җөмлә.

**Тезмә кушма җөмлә** – аерым җөмләләре үзара тезү юлы белән бәйләнгән кушма җөмлә.

**Тезмә хәбәр** – фразеологик яки бу очракта аерым кисәкләргә таркалмый торган синтаксик сүзтезмә белән бирелгән хәбәр.

**Тезүле бәйләнеш** – сүзләрнең бер-берсенә буйсынмыйча, үзара тигез хокукта килүләре.

**Тезүле тезем** – санау бүлеге төп бүлеккә тезү юлы белән генә бәйләнгән тезем.

**Текст** – өйрәнү өчен алынган, эчтәлек һәм структур яктан оешкан тоташ сөйләм.

**Текст композициясе** – текстның билгеле бер эзлеклелектәге план белән оештырылуы.

**Тел** – аралашу коралы.

**Теркәгечле тезмә кушма җөмлә** – компонентлары теркәгечләр аша бәйләнгән кушма җөмлә.

**Теркәгечсез тезмә кушма җөмлә** – компонентлары интонация аша бәйләнгән кушма җөмлә.

**Тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә** – ике яки икедән артык иярчен җөмлә бер баш җөмләгә ияреп килеп, ул җөмләләр үзара тиңдәш булган кушма җөмлә.

**Тиңдәш кисәкләр** – нинди дә булса бер кисәккә караган һәм шул кисәккә карата бер үк мәгънә мөнәсәбәтендә торган кисәкләр.

**Тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә** – ике яки икедән артык иярчен җөмләнең баш җөмләне төрле яктан ачыклап килүе.

**Тойгы басымы** – көчле тойгы белән әйтелгән җөмләләрдә аерым сүзләргә төшә торган басым.

**Тойгылы боеру җөмлә** – формасы белән боеру җөмләгә охшаган, ләкин боеру төрле тойгыларга, эчке кичерешләргә бай булган җөмлә.

**Тойгылы җөмлә** – көчле тойгы белән әйтелә торган җөмлә.

**Тойгылы сорау җөмлә** – формасы белән сорау җөмләгә охшаган, ләкин төрле тойгыларны, кичерешләрне белдерә торган җөмлә.

**Тойгылы хикәя җөмлә** – формасы белән генә хикәя җөмләгә охшаган, ләкин нинди дә булса күренешне зур тойгы белән хәбәр итә торган җөмлә.

**Төгәлләүле мөнәсәбәт** – иярүче сүзнең ияртүче сүздән аңлашылган әйберне (төшенчәне) шуңа охшаган башка әйберләрдән (төшенчәләрдән) аерып, конкретлаштырып килүе.

**Төшмә тезем** – иң элек санау бүлеге, аннан соң төп бүлек килгән тезем.

**Төшүче интонация** – үзенең югары ноктасыннан әкренләп төшеп бара торган интонация.

**Тулы җөмлә** – мәгънә тулылыгы өчен кирәк булган барлык җөмлә кисәкләре дә файдаланылган җөмлә.

**Тулы интонация** – күтәрелү өлеше, югары ноктасы һәм төшү өлеше булган интонация.

**Туры сөйләм** – үзгәртелмичә кулланылган чит сөйләм.

**Туры тәмамлык** – процесс турыдан-туры кагыла торган әйберне, төшенчәне белдергән тәмамлык.

**Уртак сөйләм** – автор һәм персонаж (чит кеше) өчен уртак сөйләм.

**Урын тезем** – санау бүлеге урын хәлләреннән яки урын җөмләләрдән тора торган тезем.

**Урын хәле** – процессның яки билгенең булу яки юнәлү урынын белдерә торган иярчен кисәк.

**Фигыль хәбәр** – фигыль белән генә белдерелгән хәбәр.

**Фраза басымы** – бер яки мәгънә ягыннан бәйләнгән берничә сүзне (синтагманы) бер басым белән әйтү.

**Фразеологик сүзтезмә** – кисәкләре арасындагы реаль мәгънә мөнәсәбәте югалган һәм шуның нәтиҗәсендә ныгып калган сүзтезмә.

**Хәбәр** – җөмләнең ия турында хәбәр итә һәм аңа грамматик буйсына торган баш кисәк.

**Хәбәр тезем** – санау бүлеге хәбәрләрдән яки хәбәр җөмләләрдән тора торган тезем.

**Хәбәрлек** – сөйләмнең хәбәр итү үзенчәлеге.

**Хәбәрлекле мөнәсәбәт** – иярүче сүзнең (хәбәр) ияртүче сүз (ия) белдергән төшенчә турында нинди дә булса бер яңалык хәбәр итүе.

**Хәл** – җөмләнең фигыль, сыйфат, рәвеш һәм процесс белдерә торган башка сүзләр белән бирелгән кисәгенә ияреп, процессның яки билгенең

билгесен яисә процессның үтәлү рәвешен, вакытын, урынын, юнәлешен, максатын, сәбәбен, шартын, күләм-дәрәҗәсен белдерә торган иярчен кисәк.

**Хикәя җөмлә** – чынбарлыкта булган күренешләр, әйберләр турында хәбәр итә торган җөмлә.

**Хөкемләүнең предикатын белдерә торган сүз** – логик басым төшә торган сүз, ягъни тыңлаучы өчен яңа төшенчә.

**Цитата** – язма әсәрләрдән алынган туры сөйләм.

**Чит сөйләм** – тест эченә килеп кергән башка кеше сүзләре.

**Чын сорау җөмлә** – җавап таләп итә торган сорау җөмлә.

**Чынбарлык** – фәлсәфи мәгънәдә кеше аңыннан тыш реаль яши торган күренешләр.

**Шарт тезем** – санау бүлеге шарт хәлләреннән яки шарт җөмләләрдән тора торган тезем.

**Шарт хәле** – ияртүче кисәктән аңлашылган процессның үтәлү-үтәлмәвенә шарт булып килгән процессны белдерә торган иярчен кисәк.

**Эндәш сүз** – сөйләм төбәлгән затны, әйберне белдерә торган сүз.

**Эндәшле тезем** – санау бүлеге эндәш сүзләрдән генә торган тезем.

**Янәшәлек** – хәл фигыль, шарт фигыль, сыйфат фигыль кушымчалары, кайбер сыйфат һәм рәвеш ясагыч кушымчалар, тартым кушымчасы, мөнәсәбәтле сүзләр, ияртүче теркәгечләр, сүз тәртибе, интонация, янәшә тору һәм лексик мәгънә аша бәйләнеш.

**Ярашу** – ияртүче сүзнең үзенең формаларын ияртүче сүз формасына карап яраштыруы.